СЫЙЛЫ АВЫЛ

Яңа Думада 688 баш мөгезле эре терлек тоталар, бирөдә 4 көтү чыга

> 5

КИТАП КУШКАНЧА

Хәләл тормыш алып баруның өстенлекләре нидә?

> 16

РАИЛ САДРИЕВ:

«Җыен бозыклар герой булды, чын кешеләр күләгәдә калды»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 36 (29196) | Җомга | 22 март | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ru.freepik

ҮЗЕ КҮЧТӘНӘЧ

БАЛА ТӘРБИЯЛӘҮЧЕ ГАИЛӘЛӘРГӘ ДӘҮЛӘТТӘН НИНДИ ЯРДӘМ ЧАРАЛАРЫ КАРАЛГАН?

2024 ел илдә Гаилә елы дип игълан ителде. Гаҗәп тә түгел: соңгы елларда бала тәрбияләүче әти-әниләрне (ә без гаиләне нәкъ менә шундый итеп күзалларга гадәтләнгән) торган саен күбрәк кайгыртталар. Бер генә сан: Татарстанда 190 меңгә якын балага әле былтыр гына гамәлгә кергән Бердәм пособие түләнә. Элек дәүләттән бирелүче мондый ярдәм кесә төбеннән ары узмаса, хәзер сүз шактый саллы түләүләр турында бара. Бала тәрбияләүче гаиләләргә нинди ярдәм чаралары каралган? «ВТ» хәбәрчесе әлеге төр түләүләрне барлады.

> 6–7

Ишетми калмагыз

Сайлауга рәсми йомгак ясалды. Аның буенча, бүгенге дәүләт башлыгы Владимир Путин, бишенче тапкыр җиңеп, сайлаучыларның 87,28 проценты (76277708 кеше) тавышын җыйган. Россия Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе Элла Памфилова әйтүенчә, сайлаучыларның 77,49 проценты (113 миллион кешедән – 87576075) Президент сайлауга барган. Бүгенге Россия тарихында моңарчы күрелмәгән саннар бу.
КПРФтан кандидат Николай Харитонов икенче урынга чыккан (сайлаучыларның 4,31 проценты тавышын җыйган). «Новые люди» партиясеннән Владислав Даванков – өченче (3,85%), ЛДПР җитәкчесе Леонид Слуцкий – дүртенче (3,20%) урында.

Узган ел ачылган М12 юлын төзү 1 триллион чамасына – 910 миллиард сумга төшкән. Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин әйтүенчә, инде аны салганда ук казнага 350 миллиард сумлык салым кергән. Аның сүзләренә караганда, якындагы 20 ел эчендә юлдан һәм аңа бәйле башка оешмалар эшчәнлегеннән бюджетка 1,8 триллион сум күләмендә салым алыначак. Трассаны карап тоту кыйммәткә төшсә дә (елына аны төзүгә тотылган акчаның 5 проценты чамасы), төзелеш чыгымнарын тулысынча каплаячак, дигән сүз бу.

Татарстан Хөкүмәте 22 апрельдән республика территориясендә янгынга каршы махсус режим кертергә ниятли. Әлегә карар проекты тикшерү уза. Бу чорда учак кабызу, көнкүреш калдыкларын, чүпчар, корыган үлән, ботак яндыру тыела. Урманга якын урнашкан торак пунктларда, бакча ширкәтләре яки балалар лагерьларында мангалда, янмый торган башка савытта шашлык кебек ризыклар әзерләргә ярамый. Әмма бу чикләү ресторан-кафеларга, башка җәмәгать туклануы объектларына кагылмый.

Татарстанда явым-төшемсез, төнлә –18 градуска кадәр суык, көндез +8 градуска кадәр җылы алып килгән антициклонны төньяк-көнбатыштан үтеп кергән циклон алыштыра. Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, шимбә – 23 мартта һава температурасы көндез +2...+7 градус тәшкил итәчәк. Төнге сәгатьләрдә –4...–9, урыны белән –15 градуска кадәр төшәчәк. Якшәмбе – 24 мартта җепшек кар һәм яңгыр көтелә. Көньяк-көнбатыштан секундына 15 метрга кадәр тизлектә җил. Көндез +2...+7, төнге сәгатьләрдә –3...+2 градус.
Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, киләсе атна башында җепшек кар һәм яңгыр булачак. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +4...+9, төнлә –4...+1 градус күрсәтәчәк.
Сак булыгыз: явым-төшемле җылы һава биналар түбәсеннән, башка авыш өслекләрдән бозлы кар төшүгә, шулай ук карның тизрәк эрүенә китерергә мөмкин.

Районнарда ни хәлләр?

Менделеевск

Рамазан аеның соңгы ун көнендә Менделеевск мөхтәсибәтендә 5–15 яшьлек балалар һәм үсмерләр арасында бәйге уткәрелә. Аның шартлары буенча, район Үзәк мәчетенә көн саен тәравих намазларына йөрүче балаларның кыйммәтле бүләкләр – велосипед, телефон, планшет алу мөмкинлеге бар. Әлеге бәйге Менделеевск мөхтәсибәте тарафыннан район иганәчеләре белән берлектә оештырыла. Аның нәтиҗәләре, рамазан ае тәмамланганнан соң, район башлыгы Радмир Беляев һәм имам-мөхтәсиб Ирек хәзрәт Нуриев катнашында Ураза гаете көнне игълан ителәчәк.
(«Татар-информ»)

Кукмара

Апрельдә Кукмара районының «Хезмәт даны» газетасы редакциясендә удмурт телендә «Вамыш» газетасы чыга башлый. Ул, рус телендәге «Трудовая слава» газетасыннан тәрҗемә ителеп, 8 полосалы булып чыгачак. «Бик тиздән без «Вамыш» удмурт газетасына язылу кампаниясенең башлануы турында игълан итәчәкбез. Бер айга язылу бәясе 85 сумны тәшкил итә. Икенче яртыеллыктан почта бүлекчәләре аша язылырга мөмкин булачак», – дип сөйләде газетаның баш мөхәррире Эльвира Миңнеәхмәтова.
(«Хезмәт даны»)

Чаллы

Шәһәр халкы быел яңартылган пляжда ял итә алачак. Сүз ГЭС бистәсендә урнашкан су коену урыны хакында. Бирегә 500 тонна яңа ком алып киләчәкләр, заманча объектлар, шул исәптән күзәтү каланчалары, медпункт булдырачаклар. Шулай ук агачтан ясалган 500 шезлонг һәм кояштан саклаучы зонтлар куячаклар. Моннан тыш мунча һәм 100 балага исәпләнгән кабартылган бассейн да урнаштыру күздә тотыла. Урында туклану зоналарын кора башлаганнар. Яңа пляжны быелның май аенда ачарга исәп тоталар.
(«Шәһри Чаллы»)

Әлмәт

Әлмәттә яшәүче Альберт Җәләлтдинов «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме – 2023» конкурсында «Техник фәннәр өлкәсендә иң яхшы яшь галим» дип танылды. Нефть югары мәктәбенең фәнни-техник тикшеренүләр үзәге башлыгы җюрига үз эшләнмәсен – бетонның яңа төрен тәкъдим итте. Яңа материал бернигә сыйфаты белән аерылып тора: ул башкалардан 10 процентка ныграк, аның составына азрак цемент керә, бу исә аның бәясен киметә. Шулай ук яңа бетон парник газын киметә һәм эшкәртә. Альберт Җәләлтдинов әлеге эшләнмәсенә махсус җайланма булдыру өчен грант та алган.
(«Әлмәт таңнары»)

ЗАКОНЛЫ ЯРТЫ ГАСЫР

Юбилей

Сезнең укучылар бар җирдә кирәк. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институтына 50 ел тулуга багышланган тантаналы чарада шулай дип белдерде.

– Сез республиканың югары уку йортлары арасында белем бирү ягыннан да, яшьләрне зур тормышка әзерләү ягыннан да лаеклы урын алып торасыз. Казан юридик институты үз исемен булдырды. Бередә белем бирүче мөгаллимнәрнең, хезмәткәрләрнең күпкырлы намуслы хезмәт нәтиҗәсе бу. Алар әзерләп чыгарган яшь белгечләр дә – әнә шул хезмәт нәтиҗәсе, – диде Парламент башлыгы.

Фәрит Мөхәммәтшин бу урында институт эшенә зур өлеш керткән олпат шәхесләрне дә искә алды.

– Хәзерге буын ярты гомерен юридик институт тормышына багышлаган шәхесләр традицияләренә таяна, – диде Дәүләт Советы Рәисе. – Хокук саклау тармагына кадрлар әзерләү белән беррәттән безгә дә файда китерәсез. Без, закон чыгаручылар, шулай ук сезнең хезмәттән файдаланабыз. Сезнең уку йортын тәмамлаучылар арасында депутат булып сайлаучылар да бар, алар федераль үзәккә закон проектлары эшләп җибәрүдә дә катнаша. Яшермим: ил Президенты карары белән Конституциягә үзгәрешләр комиссиясенә кертелгәч тә, хокукый ярдәм сорап, сезгә мөрәҗәгать иттем.

Фәрит Мөхәммәтшинның сүзләрен тантанада катнашкан Татарстан буенча эчке эшләр министры Дамир Садретдинов та куәтләде.

– Без сезнең белән бик тыгыз элемтәдә торабыз. Бу хезмәттәшлек алга таба тагын да ныгыр дип өметләнәм. 50 яшь – кеше өчен саллы чор, уку йорты өчен исә шактый яшь вакыт. Казан юридик институтын алда якты, матур киләчәк көтә, – диде министр.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институтына 1974 елның 21 мартында нигез салынган. Әлеге уку йорты бүген илдәге иң эре һөнәри юридик белем бирү үзәкләренең берсе санала. Ярты гасыр эчендә Казан юридик институты эчке эшләр органнарына 20 меңнән артык белгеч әзерләгән. Бу уку йортын тәмамлаучыларның күбесе югары вазыйфалар били. Алар арасында 15 генерал, федераль, республика дәрәҗәсендәге җитәкчеләр бар. Узган ел институтта 4 меңнән артык курсант белем алган.

ЯРЛАРЫННАН ТАШСА ЕЛГА...

Яз – 2024

Татарстанда язгы ташуга бәйле вазгыять әле куркыныч түгел. Бу хакта Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсенең кризислы ситуацияләр үзәге җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Андрей Елизаров матбугат очрашуында хәбәр итте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Су күтәрелгән очракта республикада 220 торак пунктны, ягъни 13636 кеше яшәгән йортларны су басачак дигән сүз бу. Елгалар ярларыннан чыкса, социаль әһәмияткә ия 10 объектны, 30,2 чакрымга сузылган 47 юл мәйданы, 22 күперне су басачак. Тимер юлларга, агу складлары, сәнәгать калдыкларын саклау урыннары, үләт базлары, су корылмаларына куркыныч янамый.

– Татарстанда гидрологик хәл нормада. 2023 елның җәйге-көзге чорында ташуга әзерлек эшләре башкарылды. Моның өчен 988 миллион сум тотылды. Әмма быел башка еллардан аермалы буларак, кар күп яуды. Республикада аның биеклеге уртача 61 сантиметрны тәшкил итте. Әлегә елгалар ачылмады. Без язгы ташуны апрельнең икенче яртысында булыр дип көтәбез, – диде Андрей Елизаров.

Белгеч фикеренчә, ташуның ничек булуы һава торышыннан һәм карның нинди тизлектә эрүеннән торачак. Әгәр кинәт кенә җылытып җибәрсә, Гөбенә, Кәрлә, Бөрсет, Кече Чирмешән елгалары күтәреләчәк.

– Без ташуны контрольдә тотарга тырышабыз. Моның өчен вакытлыча гидропостлар эшли башлады. Шулай ук 88 оператив төркем эшләячәк, күктән дә күзәтеп торачакбыз. Техника да әзер, – ди Андрей Елизаров.

Белгеч әйтүенчә, сулыкларда боз тыгылу ихтималы булган 61 урын бар. Бозлар өелеп, суга комачау итмәсен өчен, республиканың 23 районында елгаларны чүп-чардан чистартканнар. Ә менә боз шартлату эшләре кирәклеккә карап хәл ителәчәк. Алдан хәстәрен күрүчеләр дә бар. 15 районнан боз шартлатырга дип гариза килгән инде.

Су баскан очракта, республиканың 8 торак пунктына юллар өзелергә мөмкин. Болар – Буа районының Бәбки, Арча районының Кәче, Нурлат районының Үрнәк, Яңа Чишмә районының Архангел бистәсе, Теләчедә Екатериновка, Югары Осланда Куралово, Биектау районының Байкал һәм Тимофеевка авыллары.

Йортларына су керсә, 40 мең кешене сыйдыра торган 158 вакытлыча тору урыны әзерләнгән.

Әлегә республикада һава торышы сөендерә. Көндезләрен бераз җылытып җибәрә, төнлә суыта. Шунлыктан кар, эреп, җиргә сеңеп бара.

Редакциягә кунакка килгән халык синоптигы, Балтач районының Яңгул авылында гомер итүче Әмир Шәрәфиевкә дә быелгы ташуга бәйле сорауны биргән идек. Ул артык борчылмаска кушты. Аның күзәтүләренә ышансаң, су артык күтәрелмәс төсле. Әмма синоптик кайбер урыннарны су басар дигән фикердә.

– Быел түң юк. Кар әкренләп эреп, сеңеп бара. Яз озакка сузылачак. Су җиргә китәргә тиеш. Өч ел инде туфрак коры иде. Уҗымнар өчен дымның күп булуы яхшы инде ул, – ди Әмир абый. – Авылга кара каргалар да килде. Әмма алар әле оя корырга җыенмый. Алар көннәр җылытканны көтә. 21 марттан соң әкренләп җылыта башлый инде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

БЕРЛӘШЕП ЭШЛИК ӘЛЕ!

Өлкәннәргә – алмаш, галимнәргә матди ярдәм кирәк. Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының Татарстанның Фәннәр академиясендә узган күчмә утырышы әнә шундый хәл ителмәгән мәсьәләләр барлыгын искә төшерде.

Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнехановның утырышның күп өлешен алып торган чыгышы тагын нәрсәләр турында иде соң? Иң элек яңа президент академия алдында торган бурычлар турында искә алды. Беренче чиратта фән, технологияләр, инновацияләр юнәлеше икътисадның реаль секторы һәм фәнни берләшмәләр белән үзара нәтиҗәле эшчәнлек алып барырга тиеш. Икенче бурыч – кызыклы тикшеренүләрне, уйлап табуларны акчалата куәтләп торган даими матди система булдыру. Өченчесе – фәнне популярлаштыру, дүртенчесе – фәнни-технологик үсеш буенча илкүләм рейтингта уңай күрсәткечләргә ирешү (2022 елда Татарстан икенче урынга менгән иде, моңа кадәр бишенче урыны биләде).

Рифкать Миңнеханов билгеләп үткәнчә, үсешкә киртә булып фәнни хезмәткәрләрнең арта бара торган уртача яше тора.

– Яшьләрне җәлеп итү, өлкәннәрне дә рәнҗетмичә кадрлар мәсьәләсендә баланс булдыру өчен, яңа алым уйлап таптык. Бу – Фәннәр академиясе профессоры исеменә конкурс. Академия профессорлары ул – актив, 50 яшькә кадәр фән докторлары, фәнни казанышлары булган кешеләр, – дип аңлатты Фәннәр академиясе президенты. – Фәннәр академиясе әгъзасы булыр өчен, димәк, яшь кандидатка үзен академия профессоры вазыйфасында сынап карарга кирәк булачак.

Академия президенты әйткән тагын бер яңалык: Татарстанда галимнәр, сәнәгатьчеләр һәм эшмәкәрләрне берләштергән уртак бизнес-киңлек булдырылачак. Мондый мәйданчыкны булдыру Татарстанда расланган фәнни-технологик үсеш программасы кысасында планлаштырыла.

Максат-бурычлар белән бергә әлеге авырткан җирләргә дә төртеп күрсәттеләр. Милли кадрлар әзерләү мәсьәләсенә бәйле иде ул. Хәзерге вакытта татар филологиясе һәм тарих юнәлешләре өчен милли кадрлар әзерләү кыенлаша башлады. Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты Айнур Тимерханов шулай дип белдерде.

Айнур Тимерханов әйтүенчә, бүген татар филологиясе һәм тарих юнәлешләрендә белем алган студентларны аспирантурага җәлеп итү эше дә авыррак бара.

– Бу юнәлешләрдә аспирантурага милли кадрлар әзерләү кискенләшә башлады. Сер түгел, илдә татар филологиясе һәм тарих юнәлешендә эшләп килгән бүлекләр инде ябыла, бу юнәлешләрдә белем алган студентларны аспирантурага җәлеп итү дә кими. Бу – җитди проблема, – диде ул. – Болай барса, берничә елдан соң урта буын галимнәр, алмаш калмаячак та. Алар бит хәзер пенсия яшендә булучыларга алмашка килергә әзер торырга тиеш.

Фән, алгарыш дия-дия, гуманитар өлкәнең күләгәдә кала баруы берәүгә дә сер түгел. Кем әйтмешли, сорау булмагач, ихтыяҗы да...

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

tatar-inform.ru

ОЯТЫН КАЯ КУЯСЫҢ?

Рольләр үзгәрде: бала урынында – әти-әниләр. Кичә Татарстанда «Бергәләп тапшырабыз» акциясе үтте. Әти-әниләр тарих фәненнән бердәм дәүләт имтиханын бирде.

Казандагы 139 нчы гимназиягә Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин да килгән иде. Кулларында – паспорт. Артык бер әйбер дә алып керергә ярамый. Әти-әниләрнең телефоннарын бер тартмага җыйдылар. Металл эзләгеч аша кергәндә, берәүнең чалбар каешының тимере чыңлады. Әти кешегә аны салырга туры килде. Нишләтәсең, тәртибе шундый.

Татарстан Дәүләт Советы депутаты Динар Бариев 2007 елда БДИны укучы буларак тапшырган. Ә бүген ул – башка рольдә. Ул чакта тарихтан ничә балл җыйганын оныткан инде. Билгегә кучерсәң, «4ле»лек. Тарих, җәмгыять белеменнән сынаулар биреп, юристлыкка укырга кергән.

– Ул вакыт белән чагыштырганда, күп әйберләр үзгәрде. Шуңа күрә белемемне тикшерү миңа кызык. Дулкынлану бар. Әзерләнмәсәм дә, балларым яхшы булыр дип өметләнәм, – ди Динар Бариев.

Илсур Һадиуллин сынау алдыннан акциянең асылын аңлатты.

– Имтихан турында төрле фикерләр бар. Шуңа күрә кайбер әти-әниләр аңлап та бетермәскә мөмкин. Максатыбыз – тагын бер кат БДИ үткәрү ысуллары, аның мәгънәсе белән таныштыру. Әти-әниләр ул-кызларының ничек итеп имтихан бирүен үзләре кичереп караячак. Куркыныч әйбер юк. Психологик ярдәм мәктәптә ел дәвамында алып барыла, – диде министр.

Катлаулы булганмы? Имтиханнан соң министр үз фикерләрен әйтте. Илсур Һадиуллин белдергәнчә, бер кешене дә куып чыгармаганнар. Бернинди шпаргалка да тапмаганнар, димәк.

– Оятка калмас өчен, елларда тарихтагы төп вакыйгаларны искә төшердем. Имтиханга әзерләндем. Журналистлар: «Һадиуллин үзе балаларны имтиханны яхшы бирергә өнди, ә үзе берни белми», – дисә, бик күңелсез бит, – диде министр, берни яшермичә. – Тугыз сорауның берсе хәрби операциягә бәйле иде. Биремнәр илдәге вакыйгаларга карап үзгәрә. Курск сугышы, аның этапларына кагылышлы бирем бар иде. Сораулар – мәктәп белеме дәрәҗәсендә. Җавап бирмәслек бер әйбер дә юк.

Сәрия МИФТАХОВА

Сан

Быел республикада 11 нче сыйныфны – **14 мең**, ә 9 нчы сыйныфны **46 мең**нән артык укучы тәмамлый. Тарихтан имтиханны **2800 укучы** сайлаган.

Язучы сүзе

Җинаятьче

Бер мәлне авылдан ит китерделәр. Сыерныкын. Арт саны белән бергә кабыргаларын да сораган идек. Кыш көне генә җайлы ул, беркадәр туңган, җилләгән була. Ә җәй көне алай түгел. Өстәвенә кискәләп тә тормый гына алып килгәннәр.

Кыскасы, моны эссе җәй көнендә фатирда тураклап, суыткычка тутырырга кирәк. Өйне пычратасы килми хәзер, хатынның да өйдә чагы түгел. Үзенә җыештырырга туры киләчәген белсә, ир-аттан да пөхтәрәк җан иясе булмый. Ир кеше бит ул хәтта ашаган тәлинкәсен юып куюны да зур эшкә исәпли. Чынлап та шулай, тәлинкәңне юып куясың, кулларыңны сөртәсең һәм кашыгыңның юылмыйча калганын күрәсең. Анысын юсаң, тагын нәрсәдер калган булып чыга. Кухняның үз холкы бар аның һәм һәрвакыт хатынның кадерен белдерер өчен тырышадыр, шуңа күрә гел сиңа аркылы эшлидер кебек тоела.

Кухня өстәлендә аз гына торган арада да теге итнең сүле агып, өстәлгә тамчылый башлады. Һәм мин ике дә уйламыйча, моны ваннага илтеп салдым. Альяпкыч киеп, зур пычак тотып, ит турарга кереп киттем. Башта кабыргаларны эш итәргә кирәк. Алары канлырак та, җайсызрак та. Кискәлим инде хәзер боларны. Әзер булган калҗаларны коридорда торган зур табакка ыргытам. Пөхтә булырга тырышсам да, каны да, вак кисәкчекләре дә чәчри инде тирә-якка. Көн дә эшләп өйрәнмәгән эшне беркайчан да пөхтә итеп ерып чыгып булмый торгандыр. Кыеграк чапкан чакларда, бик яман итмичә генә сүгенеп тә алам. Барыбер файдасы тими. Кайбер сөякләрен бәләкәй пычкы белән өзәм, кайберләрен балта белән чабарга туры килә. Ваннада тавыш болай да яңгырый, ә монда шап та шоп килеп тора барысы да. Идәнгә куеп чапкач, аскы каттагы күршеләрнең түшәмендәге люстралар селкенеп торадыр инде.

Чынлап та шулай булган бугай. Бер мәлне ишектә кыңгырау шалтырый. Мин аны-моны уйламыйча барып ачам. Чынлап та, аскы каттагы күрше хатыны. Өлкән яшьтә инде ул, шуңа кыяфәте күзне сөендерерлек түгел. Тавышы да яман. Холкы да. Хәзер ул исәнләшеп тә тормастан, мине гаепләп кычкыра башлаячак, дөньядагы бер сүзне дә калдырмыйча сукрана-сукрана беркадәр җанны кимергәч, үз эшеннән тулысынча канәгать булып, Берлинны алган кыяфәттә төшеп китәчәк...

Тик алай булып чыкмады. Күрше хатыны, мине күргәч, бик яман кычкырырга дип ачкан авызы турында тәмам онытып тынып калды да күзләрен шарга әйләндерде. Күзләре чынлап та өреп кабарткан шар шикелле зурая барып, маңгай тирәсенә шуыша башладылар. Ул сулыш алырга тукталып куйды, тик авызын тагы да зуррак ачудан уза алмады һәм агачка әйләнгән аякларында артка чигенә башлады. Мин аны авырып киткәндер, «ашыгыч ярдәм» чакырырга кирәктер дип, фатир эченә борылып, карашым белән телефонны эзләгән арада, ул, фырт итеп, күздән югалды. Бары тик баскычлар мәйданчыгында аның саңгырау тавышы гына эленеп калды.

Мин кабат эшкә тотыныр алдыннан көзгегә күз салдым да бер мизгелгә тукталып калдым. Кыяфәт бик гүзәл түгел икән. Беләкләргә кадәр канга баткан, хәтта маңгай тирәсендә дә кызыл таплар, ит кисәкчекләре чәчрәгән. Ә алъяпкычны инде әйтеп тә торасы түгел. Ярый инде, юасын юармын, рәте калмаганын чүп савытына ташлармын.

Беркадәр вакыт үтүгә, ишектә тагын кыңгырау шалтырады. Мин барып ачтым. Полиция формасы кигән кешеләрне генә абайлап калдым, алар атылып кердиләр дә кулларыны артка каерып, идәнгә сузып салдылар. Мин ни икәнен төшенеп өлгергәнче, алар хәлне аңлап алдылар. Сак кына ычкындырдылар...

Күрше хатыны бая, минем кыяфәтне күргәч, полиция чакырган булган. Кемнедер үтереп, тураклап ята икән дип уйлаган. Көлештек азактан. Шулай да хәтерем калды. Күршең турында шул дәрәҗәдә түбән уйда булу – бик начар күренеш. Үтергән кешеләрне үз фатирымда тураклап ятарга ахмакмыни инде мин...

Марат КӘБИРОВ

Әйтеп кенә бактым

Йөриләр инде шунда

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Быел тавыш бирергә сайлауның беренче көнендә үк бармакчы идек. Оныгыбыз Кәрим: «Мине дә алыгыз әле!» – диде.

– Без бит иртүк барабыз, улым, ә синең иртәнге сигезгә үк мәктәпкә китәсең бар.

– Алайса, әйдә, шимбә көнне барыйк, – ди бу.

Ун яше дә тулмаган балага нәрсәгә инде бу сайлау? Үзем шулай дип уйлыйм, шул ук вакытта баланың нинди дер зур вакыйга көткәнен дә сизәм.

Бардык без тавыш бирергә. Кәрим телəгәнчә, шимбә көнне бардык.

Бюллетень алдык та: «Кемне сайлыйбыз соң, улым?» – дигән булам.

– Путинны, конечно.

– Мә алайса, менә бу шакмакка берәр билге куй!

Кәрим аптырап калды: «Син нәрсә, дәү әти, миңа унсигез тулмады бит әле, закон нарушать нельзя», – ди.

«И-и улым, бигрәк иртә өлгергәнсең бугай инде», – дип, башыннан сыйпыйм.

Икенче көнне әтисе белән дә сайлауга барып кайтты Кәрим. Дөрес, бина эченә кереп тормаган, әтисенә тавыш бирү бүлмәсен ничек табарга икәнен өйрәтеп, урамда калган.

Балачакта без дә сайлауны көтеп ала, өлкәннәр белән бергә бәйрәм итә идек. Ул көнне клубта «авыл үзешчәннәре көче белән» зур концерт та була иде. Анда да катнаштык. Сәхнәдә биш-алты бала тезелеп басып:

«Бабай, сиңа ничә яшьтер,
Миңа тула унсигез.
Сайлауларда катнашабыз,
Икебез дә бертигез...» –

дип каравыл кычкырып җырлаулар бүген дә хәтердә әле. Укытучы апа кычкырып җырларга кушкач, шул хәтле акырганбыздыр, күрәсең, бездән яшелле-зәңгәрле тавышлар чыга иде. Әмма авыл халкы һәрвакыт гөрләтеп кул чапты.

Хәзер заман башка, кешеләр дә икенчерәк кебек. Бәлки, миңа гына шулай тоеладыр, бүгенге кешеләр дә ил кайгысы, ил шатлыгы белән яшидер. Шуңа ышанасы килә. Әмма... Бу сайлау алдыннан да сайлау участогы комиссиясеннән ике ханым өй борынча йөреп, халыкны барладылар. Безгә дә килде алар, әмма бер фатир хуҗасы: «Без катнашмыйбыз», – дип, тегеләрнең борын төбендә ишеген ябып куйды.

Дөресен әйтим, гарьләндем мин аның өчен. Каян килгән аңа бу кадәр битарафлык, ваемсызлык? Юкса, тормышлары да җитеш. Русның мәшһүр язучысы, талантлы сатирик Михаил Салтыков-Щедрин: «Ил, кешеләр язмышына битараф булганнардан да куркыныч зат юк», – дигәнрәк сүзләр язып калдырган.

Быелгы сайлау ил халкының бердәм булуын күрсәтте, дип шатландык. Илгә авырлык килгәндә, куркыныч янаганда туплана белү әйбәт инде ул. Ә тыныч вакытта без нинди булырга тиеш? Һаман сугыш-чуалышлар көтеп кенә яшәргә микәнни? Кем икәнен оныттым инде, әлеге дә баягы акыл ияләренең берсе Җир йөзендә хыянәт, үтерү-сугышларны нәкъ менә ваемсызлык тудыруы турында әйтеп калдырган. Мин бу сүзләр сайлауда катнашмаулары белән мактанып йөрүчеләр колагына кермәс микән дип язам. Андыйлар үзләрен сәяси җитлеккән, кыю кеше дип саный һәм «сайлау дип йөргән булалар шунда, безнең өчен күптән сайлап куйганнар инде...» кебек сүзләрне уңга-сулга чәчеп йөрү алар өчен берни дә тормый. Андыйлар турында үземнең дә: «Йөргән булалар шунда», – дип әйтеп куясы килә.

Оныгым Кәрим миннән сайлауның тагын кайчан буласын сорады.

– Сиңа нәрсәгә ул?

– Тизрәк үсәсе килә, дәү әти, – диде.

ВАМПИРЛАР МӘҖЛЕСЕ ТӨГӘЛЛӘНГӘНДӘ

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ



Укучылар гафу итсеннәр, автор тагын моннан ундүрт ел элек «Ватаным»да басылган «Вампирлар» дигән язмасына әйләнеп кайта һәм шул язмадан цитата китерә: *«... капиталистик җәмгыять тә үзенә табут капкачын кадаклаучыны көтә башлады. ... вәхши системаның ялган пәрдәсе күзләрдән алыну белән, аның тарафыннан изелгән миллиардлар алдына «Инде нишләргә?» дигән хәлиткеч сорау килеп басачак. Әлбәттә, бу сорау бөтен кискенлеге белән куелганчы, кешелек җәмгыяте тетрәндергеч фаҗигаләр, кискен югалтулар кичерәчәк, ачлыктан, сугышлардан, бертуктаусыз дәвам итеп торучы террор һөҗүмнәреннән, эпидемияләр һәм табигать бәла-казаларыннан күпләр, бик күпләр баш салачак, капитализмның паразит табигате, аның үсеш мантыйгы кешелек җәмгыятен глобаль катастрофага китереп терәячәк».*

Хәзер, әйдәгез, Путинга сүз бирик. «Әмма Көнбатыш элитасы халыкара эшләрдә бүгенге гаделсезлекне саклап калырга хыяллана. Алар йөзләрчә еллар буе корсакларын – кеше каны белән, ә кесәләрен акча белән тутырырга күнеккән. Ләкин алар канэчкечләр мәҗлесенең тәмамланып килүен аңларга тиеш». Кремль лидеры бу сүзләрне моннан бер атна элек журналист Дмитрий Киселев белән әңгәмәсе вакытында әйтте. Фикерләрдә никадәр тәңгәллек, әйтерсең Кремль спичрайтерлары безнең «Ватаным Татарстан»ны карап бара. Ләкин куанырга ашыкмыйк. «...канэчкечләр мәҗлесенең тәмамланып килүе» дигән фраза әйтергә генә җиңел, чынлыкта бик авыр һәм фаҗигале финиш көтелә. Автор тагын бер нәрсәне искәртә: Путин элиталарның корсакларын кеше каны белән тутырулары турында әйткәндә, туры мәгънәдә сөйли, шыттырмый да, Эзоп теле белән дә әйтми.

Бу язмада мин «мәҗлес»нең тәмамлану этабына керүенең билгеләре хакында сөйләшергә телим. Моннан нәкъ дүрт ел элек Бөтендөнья сәламәтлек оешмасы рәсми рәвештә пандемия башлануын игълан итте дә без өйләргә бикләндек. Пандемиянең ясалма рәвештә китереп чыгарылган вирус нәтиҗәсе икәнен хәзер бик күп рәсми каналлардан ишетергә була. Аңа каршы ясалган вакциналарның сәламәтлек өчен куркыныч булуын да әйтү тыелмый. Россия вакцинасының «әтисе» академик Гинцбург Көнбатышта ясалган Pfizer һәм Moderna мРНК вакциналарының тромблар барлыкка китерүләре һәм йөрәк ялкынсынуына илтүләре хакында рәсми белдерүләр ясый. Көнбатышта үлем коэффициентының кискен сикерүен дә күпләр шуңа бәйли. Канэчкеч элиталарның пандемияне этеп мәйданга чыгаруы һәм аны мәҗбүри вакциналаштыру белән көчәйтүе глобаль капитализмның буш хәрәкәтләр ясавына бәйле иде. Коронавирус пандемия генә түгел, икътисадый түнтәрелеш тә китереп чыгарды, шуның зыкымы хәзер «бөек кризис»ны көчәйтә һәм яңа түнтәрелешкә әзерли. Һәм без «яңа пандемия» турында шау-шуга юлыгабыз. Монысының тагын да көчлерәк булачагын фаразлыйлар. Юк, нинди дер бер журналистлар түгел, үзен дөнья хуҗасы дип санаган һәм мәгълүматлы затлар сүз куерта бу хакта. Дөрес, соңгы вакытта пандемия темасы арткарак чигерелеп, зур сугыш мәүзугы алга этелә. Путин яңа гына Россия белән НАТО конфликтыннан Өченче бөтендөнья сугышына бер адым гына калачагын әйтте.

Сугыш беркемгә һәм берни гә кирәкми үзе. Аны ясалма рәвештә көн тәртибенә этеп кертәләр, чөнки без яшәгән икътисадый система дәвалап булмаслык чирле. Чирнең билгеләре тормышның барлык тармакларында да күзәтелә: бурычлар болытларга килеп терәлде, кучемсез милек базары бөтен дөньяда зур җимерелү этабында, җитештерелгән технологик продукция берни гә дә ярамый, техноген катастрофаларга китерә. Яңалыкларны күзәтеп барсагыз, дөньякүләм атаклы Boeing компаниясе самолетларының әле ишекләре төшеп калуын (чөнки болтлары яхшылап беркетелмәгән), әле шассилары эшкә яраксыз икәнен, әле пилот кәнәфиенең очучыны артка алып ташлап, самолет белән идарәдән мәхрүм итүен, яисә башка куркыныч җитешсезлекләр турында ишетер идегез. Боларның барысының да сере бик гади: компания, акча кызганып, эшкә квалификациясез белгечләр җәлеп иткән, сыйфатсыз технологик материаллар кулланган... «Ни өчен акча кызганалар?» дигән сорау кызыклы. Процент капиталына нигезләнгән икътисадта акча җитештерүгә түгел, бурычлар түләүгә китә башлады. Фикерне ике хәбәр белән нигезлик. Немец фармацевтика гиганты «Bayer»ның бурычлары аның бәясеннән артып китте, чөнки ун ел эчендә концернның кыйммәте биш тапкырдан да күбрәккә кимеде. Икенче төрле әйткәндә, биржада компаниянең акцияләре чүпкә әйләнә, ә процентлы бурычлары үсә.

Россия икътисадчыларының бер исәпләвен мисал итеп китерик. Бүген 16–19 процент белән ипотека алучылар (өстенлексез ипотеканың бәясе шундый) 20 ел эчендә 4 фатир бәясе түлиләр. Ничек уйлыйсыз: түли алмасалар, алар нишләячәк? Я коллекторлар белән сугыш сукмагына басачак, я муенына элмәк салачак. Глобаль икътисад бүген шундый хәлдә. Лидерлар халыкларны сугыш сукмагына нәкъ менә шуның өчен алып чыгарга җыена да инде. Канэчкечләр мәҗлесе төгәлләнер төгәлләнүен, әмма аны канлы туй белән тәмамларга телиләр.

Проблеманың тагын бер катлаулы ягы шунда: вазгыять табигать катаклизмнары белән катлаулана. Минем алда Америка Хәрби Һава көчләре белгечләре китергән бер мәгълүмат. «Җирнең магнит кыры, – диләр алар, – үз көченең 40 процентын югалтты. Бу акыл, эмоциональ һәм физик сәламәтлеккә начар тәэсир итә. Һәм иң мөһиме: планетаның полюслары алышыначак. Полюсларның алышынуы шарның әйләнешен капма-каршыга үзгәртәчәк. Бу хакта без «Ватаным»да уникe-унөч еллар тирәсе элек «Кояш көнбатыштан чыкса» дигән язма биргән идек. Әмма язманы укучыларны юата торган сүзләр белән төгәллим: бу катаклизм булганчы, Җирдә гаделлеккә корылган социаль система тантана итәчәк. Язманы укучыларның исән кала алганнары ул системада яшәр әле.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ҖИР УЛЛАРЫ

Утарда язгы кояш нурлары астында сыерлар мөгри, якында гына трактор гөрелтесе ишетелә, төзек, матур йортларда тормыш кайный, мәчеттә азан тавышы яңгырый, балалар, чыр-чу килеп, мәктәптән кайта. Бу авазлар – авылның йөрәк тибеше. Колхоз-совхозлар таралып, халкы төрле җирләргә эш эзләп сибелешкән елларда Аксубай районының Яңа Дума авылында яшәүчеләрнең күпчелеге муллык һәм бәрәкәтне үз җирендә тапкан.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Илгизәр Шәфигуллин: «Мал асрауның файдасы бар».

Мал-туарга бай авыл

Яңа Дума авылында 688 баш мөгезле эре терлек тоталар. Шуларның 364е – сыерлар. Ягъни һәр хуҗалыкка 5,5 баш мал туры килә. Әлеге күрсәткеч буенча авыл районда беренче урында тора. Республика буенча да ул лидерлар исемлегенә керә. Биредә 4 көтү генә бар, хәтта малларга йөрер өчен җир җитми. Авылдан көн саен 2 тоннадан артык сөт алып китәләр.

– Яңа Думада 434 кеше яши. Барысы да хәләл хезмәт белән гомер итә. Әгәр сөт бәяләре гел уйнаклап тормаса, сыер саны тагын да күбрәк булыр иде. Узган ел сөт бәяләре төшү дә, корылык та халыкның кәефен кырып алды, күршетирә авылларда шактый сыерлар бетте. Күзгә яхшы якка үзгәреш булмаган булса, бездә дә киметә башларлар иде. Тик, бәхеткә, безнекеләр ул сынауларны узып чыга алды, – диде Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы Илнур Шакиров.

Мал күп асраган хуҗалыклар дәүләт ярдәме белән 13 мини-ферма гына төзегән. Эше булгач, ашы да бар. Зур бәйрәмнәр оештырганда да шушы ныклы тормышлы гаиләләргә таянуларын әйтте җирлек башлыгы. Иң мөһиме: авылда яшь гаиләләр дә күп.

Мингатиннар

Ике бертуган Рәмис һәм Радик Мингатиннар – авылның ныклы, ышанычлы тоткалары. Фермер Рәмис Мингатинның йорты каршында бер-бер артлы тезелешеп киткән утарларны күргәч, гаҗәпләнеп тә куйдык. Ничек өлгерәләр дә каян көч табалар? Ә аның сере бик гади икән: эшеңне яратып башкару.

– Мал карауның тәме – газапта, тик яратып башкаргач, газабы-авырлыгы сизелми, арытмый да ул. Мин кечкенәдән гел мал арасында булдым, шуңа күрә башка тормышны белмим дә. Керткән хезмәтеңне санасаң, мал асрауның бервакытта да файдасы булганы юк аның. Кайда тагын тәүлегенә 25 сәгать эшлиләр? Авыр булса да, хуҗалыкны зурайттык, чөнки нәфес зур бит, – дип, рәхәтләнеп көлеп җибәрде телгә җор, сүзгә туры булган Рәмис абый.

Хуҗалыкта исә нинди генә мал юк: сыеры, танасы, бозавы, үгезе, чабыш һәм йөк ташучы атлары, сарыклары, нәселле кәҗәләре. Язын исә болар янына берничә йөз кош-кортны да өстәсәң...

> Иткә һәм сөткә яхшы бәя булса, өстәгеләр алдамаса, мал-туар асрау авылны саклап кала ала. Кызганыч, безне бит бертуктамый алдап кына торалар, – ди фермер. – Без менә хәзер, абзар тутырып, терлек җыйдык. Иртәгә сөт бәясен шап итеп төшереп куйсалар, нишлибез? Итне дә моңа кадәр 400 сумнан алып киттеләр.

Әле ярый җирләрем бар. Анысын алырга да теләмәгән идем. Район башлыгыбыз Камил Гыйльманов бик әйбәт, көчләп диярлек алдыртты, шуңа күрә хәзер запассыз торганыбыз юк. Үз техникаларыбыз бар, ашлама чәчеп ашлык үстермибез, кредит алганыбыз юк, грантны да Камил Камалович бик үгетләгәч кенә алдык. Безнең авылда халык да әйбәт, бердәм. Урлашу, бер-береңне сату, аяк чалу юк. Күмәк, зур эшләрне бергәләп башкарабыз.

Рәмис абыйның улы Рафис белән килене Язилә дә авылда калган. Шуңа күрә хуҗалыкта төп ярдәмчеләре – яшьләр. Язилә каенанасы Фирдәвес апа белән сыер сауса, ир-егетләр маллар карый. Терлекләр авырып китсә дә, табиб эзләп, күршегә керәселәре юк: Рафис системаларга кадәр куя.

– Минем мәрхүм әтием белән каенатам гомер буе якын дуслар булып яшәделәр. Мин дә кечкенәдән үк бу йортка килен булып киләсемне белдем. Хуҗалыкның зур, эшнең күп булуы да мине куркытмады, чөнки үзем дә нәкъ шундый ук гаиләдә тәрбияләндем. Кечкенәдән үк дүртәр-бишәр сыер савып үстем, – ди Язилә.

Мингатиннар 45 сыердан тәүлегенә 700–800 литр сөт савып саталар. Хәзерге көндә сөтнең литры – 31 сум. Ике балалы яшь гаилә, зур йорт җиткезеп, башка чыгарга әзерләнеп йөри икән. Инде ул йортның ишегалдына да зур сарай салып, маллар белән тутырып куйганнар.

– Узган ел сөт хаклары да кимегәч, корылык та булгач, кәефебез төшеп алган иде. Тик әтинең җирләре булгач, мал ризыгын үзебезгә җитәрлек итеп әзерли алдык. Аннан соң сөт бәяләре күтәрелеп китте. Әтиебез – бик төгәл кеше. Ул һәр эшне үз вакытында эшли һәм бездән дә шуны ук таләп итә. Малларыбыз аерым көтүдә йөргәч, җәен иртәнге 5тә торып чыгабыз да ике сәгатьтә эшне төгәллибез. Кәҗәбез икәү генә булса да, сөте үзебезгә дә, күчтәнәчкә җибәрергә дә, катыгын, каймагын, эремчеген, кортын ясарга да җитә. Иремнең төп эше булса да, хуҗалыкта аның ярдәменнән башка булмый. «Эштән кайттым бит әле», – дип ятып торышлы түгел бездә. Һәркем үз эшен белеп эшли. Иремнең ике энесе дә бик булыша, – ди Язилә.

Шәфигуллиннар

Гүзәл белән Илгизәр Шәфигуллиннарның йөзләп баш мөгезле эре терлекләре, егерме бишләп атлары, сарыклары бар. Хуҗалык зур булса да, фермер булып теркәлмәгән, чөнки мәшәкате дә, таләпләре дә зуррак, ди.

– Мал асрауның файдасы юк, дигән фикер белән килешмим. Без файдасын күрәбез, чөнки, беренчедән, терлекчелек белән күптәннән шөгыльләнәбез. Икенчедән, үз җирләребез, техникабыз бар. 35–40 сыердан тәүлегенә 550 литр сөт савып озатабыз. Бер сыер егермешәр литр сөт бирә. Литрына 31 сумнан түләгәч, аена 500 мең сумга кадәр акча керә. Ит тә сатабыз. Ярминкәдә сату файдалырак. Без канәгать, хаклар шуннан төшмәсен иде дә ул. Чыгым һәм керемнәрне санап, барлап торабыз. Чыкканы күп булса да, кереме дә яхшы, – диде Илгизәр абый.

Аның фикеренчә, мал асраган кешенең тамагы һәрвакыт тук, авылы нык булачак.

– Авылда терлек күп икән, аның киләчәгенә дә өмет бар. Кем генә килсә дә: «Авылыгыз нык әле!» – ди. Тырышмыйча берни дә булмый, терлекчелектә көнне төнгә ялгап эшләргә кирәк инде. Ләкин тормышны матур итеп алып барып та була. Без дә йортлар җиткердек, машиналарыбыз бар, балаларга ярдәм иттек. 27 ел элек, гаилә корып җибәргән вакытларда, Гүзәл унике сыерны көнгә ике тапкыр кул белән сауды. Ун ел шулай тырышты. Аннан соң акрынакрын гына барысы да җайлашты.

Раузетдиновлар

Ралия һәм Рамил Раузетдиновлар да авылдашларыннан бер дә калышмый, шулай ук абзар тутырып терлек асрыйлар. Алтмыш баш терлекнең егермесе – сыерлар.

– Яшәргә кирәк бит. Эшләгәч яшәп була. Мин күрше авылда сыер саудым. Анда эш беткәч, малларны тагын да арттырдык. Әлеге вакытта сыерларыбызның берничәсен ташлаттык, шуңа күрә көненә 250 литр сөт тапшырабыз. Аны 30 сумнан бирәбез, шуннан кимемәсен иде дә, төшә бит ул. Көтүлек җирләре кысан булу да кәефне кырмаса, терлек асрарга берни комачауламый, – диде Ралия апа.

Ике ел элек кенә дәүләт ярдәме белән сафка бастырган абзарларын да зур бер горурлык белән күрсәттеләр.

– Мондый сарайларга чыгып эшләү үзе күңелле. Барлык шартлар бар, рәхәтләнеп эшләргә саулык кына булсын, – диде Рамил абый.

Абзар тутырып мал асрауның бар мәшәкатен дә, ялсыз эшләвен дә, саулык китүен дә, җаваплылыгын да, тынгысызлыгын да бик яхшы беләбез. Тик без аралашкан кешеләрнең ник берсе зарланып карасын?! Үзләренә дә шул хакта әйткәч: «Ә ник зарланырга? Кешегә түгел, үзебезгә эшлибез бит. Бетәм дисәң, бетәсең, яшим дисәң, яшисең ул», – дип җаваплады алар.

АВЫЛДАН ВИДЕОРЕПОРТАЖ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Эльвира ВӘЛИЕВА

ҮЗЕ КҮЧТӘНӘЧ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Алдан ук шуны искәртик: барлык пособиеләр һәм ташламалар икегә аерыла. Алар федераль һәм төбәк дәрәҗәсендә билгеләнә. Гадәттә, бала пособиеләре – әнигә, бик сирәк очракта гына әтигә түләнә. Россия Социаль фонды мәгълүматларына караганда, илдә яшәүче 20 миллионга якын кеше дәүләттән ярдәм чаралары ала. Ел башында Россия Президенты Владимир Путин күпбалалы гаилә статусын раслады. Татарстанда исә гаиләләргә ярдәм чаралары тупланган махсус сайт эшли башлады.

Балалар пособиеләренең күбесе мохтаҗлык таләпләреннән чыгып билгеләнә

Рәсми эш урыны. «Нульле керем кагыйдәсе» турында ишеткәнегез бармы? Сүз әнә шул хакта бара. Ягъни дәүләттән нәрсәгә дә булса өмет итү өчен, кешенең рәсми кереме булырга тиеш. Башта салым түлисең, аннары ярдәм аласың, кыскасы. Сирәк очракта гына әти-әнигә рәсми төстә эшләмәү рөхсәт ителә. Мәсәлән, гаиләдә әти яки әни генә булса. Күпбалалы гаиләдә ике өлкән кешенең берсе генә эшләү дә җитә.

Айлык керем. Күпчелек очракта, пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына туры килгән керемен, ягъни мохтаҗлык дәрәҗәсен билгелиләр. Моның өчен хезмәт хакы, пенсия, стипендия, банк кертеменнән процент кебек барлык түләүләрне кушалар да шуны гаиләдәге кеше санына бүләләр. Ә аннары килеп чыккан санны төбәктәге яшәү минимумы белән чагыштыралар. Татарстанда ул быел 12966 сум тәшкил итә. Шуннан күбрәк акча эшлисең икән, бигайбә.

Милек. Элеккегедән аермалы буларак, хәзер гаиләгә пособие билгеләгәндә милек чикләве дә куела. Мәсәлән, торакның квадрат метрын исәпкә алалар. Биш «яшь» тулмаган, 250 һәм аннан күбрәк ат көче булган машинада йөрүчеләргә дә (зур «иномарка» хуҗалары инде бу) пособие түләнми.

●ФЕДЕРАЛЬ ТҮЛӘҮЛӘР

17 яшькә кадәр бала тәрбияләүчеләргә һәм йөкле хатын-кызларга Бердәм пособие

Яңа төр түләү узган елның 1 гыйнварында гамәлгә керде. Ул йөклелек буенча айлык акча, беренче балага 3 яшькә кадәр түләү, 3 яшьтән алып 8 яшькә кадәр һәм 8 яшьтән алып 17 яшькә кадәр балаларга пособие кебек алты төрле ярдәм чарасын берләштерде. Бер елга билгеләнә. Республикада 42,5 мең гаиләдә тәрбияләнүче 190 меңнән артык балага әлеге төр акча түләнә. Быел бу пособиегә бәйле яңалык та бар: түләү билгеләгәндә «Герой ана» мактаулы исеме булганнарга, «Ата-ана даны» ордены яки орденның медале белән бүләкләнүчеләргә бирелә торган айлык акча, 18 яше тулмаган балага ачылган банк кертеменнән процент һәм агымдагы елның 1 июненнән балигъ булмаган балалар эшләгән акча исәпкә алынмаячак.

Түләү күләме
Мохтаҗлык таләпләреннән чыгып, яшәү минимумының 50, 70 яки 100 проценты күләмендә билгеләнә. Татарстанда балаларга иң зур айлык түләү – 12741 сум, йөкле хатын-кызларга – 14317 сум

Шартлары
✓Рәсми эш урыны булу
✓Җан башына айлык кеременң яшәү минимумыннан артмавы
✓Милеккә бәйле чикләү үтәлү

Алу тәртибе
Дәүләт хезмәтләре порталы аша яки шәхсән Социаль фонд бүлекчәсенә барып, гариза язарга

«Торак шартларын яхшыртталар»

Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге идарәчесе **Эдуард ВАФИН** әйтүенчә, ана капиталын барыннан да бигрәк, торак шартларын яхшыртуга тоталар.

– Быел гына да Татарстанда яшәүче 2226 гаилә шундый карар кабул итте. Программа гамәлгә кергәннән бирле республикада 300 меңнән артык гаилә шул рәвешле торак шартларын яхшыртты. Алар кооперативка керә яки кредит рәсмиләштерә ала. Йортны банктан бурычка акча алмыйча да сафка бастырырга мөмкин. Быелдан ана капиталын таунхаус, дуплекс кебек бер дивары күршеләр белән уртак булган йортны үзгәртеп коруга тотарга да рөхсәт ителә башлады. Ана капиталын, балага өч яшь тулгач, торак шартларын яхшыртуга файдаланырга мөмкин. Дәүләт ярдәмен ипотека буенча беренчел кертем яки төп бурычны каплауга тотканда, өч яшь тулганны көтәргә кирәкми, – ди Эдуард Вафин.

Йөклелек һәм бала табу буенча пособие, ягъни декрет акчасы

Түләү бәби көтүче яки өч айга кадәрге баланы уллыкка алган эшләүче хатын-кызларга бирелә. Ул бала тапкан көнгә кадәр – 70 һәм шуннан соң 70 көнгә (140 календарь көне өчен. – **Ред.**) түләнә. Ике яки өч игезәк туса, бала табу авыр узганда, көннәр саны арта. Түләү рәсми хезмәт хакына бәйле. Аны алдан исәпләп карау өчен, соңгы ике елда алган айлык акчаны башта 730га бүләргә, килеп чыккан санны 140ка тапкырларга кирәк.

Түләү күләме
Татарстанда йөклелек һәм бала табу буенча пособиенең минималь күләме – 88565,40 сум. Хезмәт хакына карап, аның иң югары чиге быел 565562,20 сум тәшкил итә. Республикада декрет ялындагы 24,5 меңнән артык әни әлеге төр түләүне алган. Аларга 3768,8 миллион сум акча түләнгән

Шартлары
✓Рәсми эш урыны булу

Алу тәртибе
Эш урынында гариза язарга, ә рәсми эш урыны булмаса, Дәүләт хезмәтләре порталы аша яки шәхсән Социаль фонд бүлекчәсенә барып, гариза тапшырырга

1,5 яшькә кадәр бала карау буенча айлык пособие

Әти яки әнигә декрет ялы балага 3 яшь тулганчы бирелә, ә пособие яшь ярымга кадәр түләнә. Ул алдагы ике елда алган уртача хезмәт хакының 40 процентын тәшкил итә. Чикләре дә бар. Бу елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кергән яңалык нигезендә, пособие алучы эшкә чыккан очракта да, пособие югалмый.

Түләү күләме
Бу елның 1 февраленнән аның минималь күләме – 9227,24 сум, максималь күләме исә 49123,12 сум тәшкил итә

Шартлары
✓Рәсми эш урыны булу
✓Эшсезләргә, бала 2023 елга кадәр туса, минималь пособие билгеләнә. Гаиләнең кереме аз булса, ә сабый 2023 елда яки аннан соң туса, әти-әни Бердәм пособиегә өмет итә ала

Алу тәртибе
Эш урынында гариза язарга, ә рәсми эш урыны булмаса, Дәүләт хезмәтләре порталы аша яки шәхсән Социаль фонд бүлекчәсенә барып, гариза тапшырырга

Балага өч яшь тулганчы, ана капиталыннан айлык түләү

Бу – соңгы арада гамәлгә кергән түләү. Ул гаилә акчасы тирәсендә мошенниклык очракларын киметү өчен эшләнде.

Түләү күләме
Төбәктә баланың яшәү минимумы күләмендә бирелә. Татарстанда ул – 12741 сум

Шартлары
✓Гаиләдә җан башына туры килгән айлык керем ике яшәү минимумыннан азрак булырга тиеш

Алу тәртибе
Дәүләт хезмәтләре порталы аша яки шәхсән Социаль фонд бүлекчәсенә барып, гариза язарга

Фикер

Алинә МӨДӘРИСОВА, Камал театры артисты:
– Кызыбыз Зөләйхага яңа гына яшь ярым булды. Шуңа күрә аңа диган пособиене соңгы тапкыр алдым. Бала кечкенә вакытта бу түләүнең файдасы тиде. Ана капиталы да бирделәр, аны әлегә тотмадык. Кем әйтмешли, үз вакытын көтә. Бала чыгымнары бик күп инде ул. Олы кызыбыз Зөбәйдәгә – җиде яшь, беренче сыйныфта укый. Бер яшьлегенә дә, җиде яшьлегенә дә күп кирәк. Балаларны кешечә киендерәсе, ашатасы, сәләтләрен үстерергә ярдәм итүче төрле түгәрәкләргә дә йөртәсе килә. Яшь ярымлык балага дәүләт бакчасы юк. Алмаз белән икебез дә эштә – көн буе театрда репетицияләрдә булгач, Зөләйханы түләүле бакчага бирергә мәҗбүр булдык. Яшь ярымга кадәр генә бирелә торган акча җитми, әлбәттә. Бала карау буенча пособие бирүне өч яшькә кадәр озайтсалар, бик яхшы булыр иде. Зөбәйдәне гимнастикага йөртәбез, аның да төпсез кое икәнен аңлыйсыз. Әнә шул түгәрәкләргә түләү өчен бераз төрле дәүләт ярдәме булса, шәп булыр иде.

Ана капиталы

Хәзер аны гаиләдәге беренче балага да алырга мөмкин. Ана капиталы акчасын файдалануга килгәндә, таләпләр элеккечә: дәүләт ярдәмен торак төзү яки сатып алуга, баланы укытуга, әнинең булачак пенсиясенә, инвалид балага товарлар һәм хезмәтләр сатып алуга тотарга рөхсәт ителә.

Түләү күләме
Ана капиталы 2020 елның 1 гыйнварыннан соң туган беренче балага 630 мең сум тәшкил итә. Беренче балага акча алынмаса, икенчесенә – 833 мең сум. Моңа кадәр гаиләдә туган беренче балага ана капиталы бирелгән булса, икенче сабыйга 203 мең сум өстәп түләнә

Шартлары
✓Бу елның 1 гыйнварыннан ана капиталы сабый, тугач ук, Россия гражданлыгы алган һәм нарасый дөньяга килгән вакытта әти-әнисе дә Россия гражданнары булган очракта гына бирелә

Алу тәртибе
Сертификат үзеннән-үзе билгеләнә

Күпбалалы гаиләгә ипотека түләве өчен субсидия

2019 елның 1 гыйнварыннан соң өченче һәм аннан соңгы бала алып кайткан, ипотека торагы булган гаиләләргә бирелә. Өлкән балаларның яше исәпкә алынмый.

Түләү күләме
Дәүләт ярдәме ипотека буенча бурычны каплау хисабына 450 мең сум тәшкил итә

Шартлары
✓Акчаны бер тапкыр гына алырга мөмкин;
✓Россия гражданлыгы булырга тиеш

Алу тәртибе
Дәүләт хезмәтләре порталы аша гариза язарга яки банкка мөрәҗәгать итәргә

●ТАТАРСТАН ТҮЛӘҮЛӘРЕ

18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә

✓Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә киткән чыгымнарның 30 проценты күләмендә субсидия.
✓Алты яшькә кадәрге балага дарулар сатып алырга субсидия (2024 елда әлеге төр түләү 164 сум тәшкил итә).
✓Мәктәп укучыларына һәм көллият, техникум студентларына, 18 яше тулганчы, юлда йөрү өчен айлык субсидия (2024 елда – 369 сум).

Алу тәртибе
Гаризаны Дәүләт хезмәтләре порталы аша юлларга мөмкин.

Өч һәм аннан да күбрәк игезәк бала табучыларга

✓Өч һәм аннан да күбрәк игезәк бала табучыларга сабыйларның һәркайсына 10000 сум күләмендә бер тапкыр пособие бирелә.
✓Өч һәм аннан да күбрәк игезәк балаһы яшь ярымга кадәр тәрбияләүчеләргә сабыйларның һәркайсына 1000 сум күләмендә айлык акча түләнә.

Алу тәртибе
Гаризаны Дәүләт хезмәтләре порталы аша юлларга мөмкин.

Авылда яшәүче әниләргә

✓Беренче баласын тапканчы, кимендә өч ел авылда яшәгән 25 яшькә кадәрге әниләргә бер тапкыр 50 мең сум бирелә.
✓Өченче һәм аннан соңгы баласын тапканчы, кимендә өч ел авылда яшәгән 29 яшькә кадәрге әниләргә бер тапкыр 100 мең сум түләнә.

Алу тәртибе
Яшәү урыны буенча «Республика матди ярдәм үзәге»нә мөрәҗәгать итәргә

Аз керемле гаиләләргә ярдәм

✓Бала тугач, бүләк комплекты тапшыралар.
✓Өч яшькә кадәрге балага дару сатып алырга елына 10 мең сумлык электрон сертификат бирелә.

Алу тәртибе
Иң элек аз керемле гаилә икәнен раслаучы документ кирәк.

Сораштыру *«ВТ»ның «ВКонтакте» төркемендә үткәрелде*



Бала тәрбияләүче гаиләләргә дәүләттән ярдәм чаралары турында беләсезме? (процентларда)

- Беләм, балага түләүләр алабыз.................................10
- Беләм, тик безгә пособие-ташламалар чыкмый.........69
- Ишеткән бар, белешкән юк.......................................14
- Юк, кем тапкан – шул баксын.....................................7

ХАЛЫК АВАЗЫ

29 мартта сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Зөһрә САДЫЙКОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

Өстәмә түләнәме?

Киявем авыл хуҗалыгы өлкәсендә 30 елдан артык механизатор булып эшләде. Хәзер аңа – 62 яшь. Авыл хуҗалыгында утыз елдан артык эшләүчеләрнең пенсиясенә өстәмә акча түләнә дип ишеткән идем. Бу дөресме?

Фаил МИНҺАҖЕВ.
Казан

Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге матбугат үзәге:
– 1962 елгы ир-атлар 64 яшендә, ягъни 2026 елда пенсиягә чыга ала. Теләсә нинди эш һәм теләсә нинди чор ташламалы авыл хуҗалыгы стажына кертелми. Гражданның белгечлеге эш, җитештерү, һөнәр, вазыйфалар һәм белгечлекләр исемлеге белән аталырга тиеш. Исемлек 500дән артык һөнәрдән – авыл хуҗалыгы предприятиеләре, колхоз, фермер хуҗалыклары хезмәткәрләре вазыйфаларыннан тора. Бу – машина-трактор станцияләре, хуҗалыкларда эшләүче оешмалар, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре (гади хезмәткәрләр генә түгел, җитәкчеләр дә), шулай ук охшаш белгечлекләр вәкилләре дә (инженер, гидротехник, мелиоратор, энергетик). Иң мөһиме – эш урынының авыл хуҗалыгы предприятиесенә каравы. Әгәр гражданның стажы һәм авыл хуҗалыгында белгечлеге исемлек һәм документлар белән расланса, пенсиягә авыл стажы өчен өстәмә билгеләнәчәк. Бу картлык һәм инвалидлык буенча иминият пенсиясенә теркәлгән түләү күләмен 25 процентка арттырачак.

Мәетне ник яралар?

Безнең авылда 12 мартта 90 яшьлек бабай – Мөнәвир абый вафат булды. Бабайны моргка алып китеп, 13 март көнне төштән соң гына ярып бирделәр. Кичке бишенче яртыда өенә алып кайттылар. Юып, кәфенләп, ишегалдына алып чыкканда, авыз ачарга вакыт җиткән иде. Бу беренче генә очрак түгел. Олы яшьтәгеләрне ник яралар? Үлгән кешегә дә, тере кешегә дә рәт юк. Бакыйлыкка күчкән кешеләрне шулай төнлә җирләргә микәнни хәзер? Зәй шәһәрендәге тәртипсезлекне туктатырга кирәк.

ГҮЗӘЛ.
Зәй районының Кушъелга авылы

Редакциядән. Охшаш сорауга җавапны газетабызның 8 март санында биргән идек. 16 февраль санында чыккан «Югалту ачысы» язмасында исә мәетне ярдыру тәртибе, бу мәсьәләгә карата белгечләрнең фикерләрен туплап, зур язма әзерләдек. Канун һәм дини тәртипләр Зәйдә дә, башка районнарда да бер булырга тиеш дип беләбез.

Теш куяларммы?

Мин – хезмәт ветераны. Безгә бушлай теш дәваларга, стоматологик протезлар ясатырга була дип ишеткән идем. Андый нәрсә бармы?

ӘЛФИЯ.
Азнакай

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат үзәге:
– Теш дәвалау һәм протезлар ясату (кыйммәтле металл һәм металл-керамикаларның хакын түләү чыгымнарыннан тыш, ясау һәм ремонт өчен) гражданнарның ташламалы категорияләренә кагыла. Болар – хезмәт ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, «Ана даны» медале булган һәм башка затлар. Әлеге хезмәт күрсәтүдән өч елга бер тапкыр файдаланып була. Теш протезлары ясауны Сәламәтлек саклау министрлыгы план буенча билгели. Әлеге план чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Тәкъдим

ЯХШЫ ҮРНӘК

Һәр милләтнең үз теле, гореф-гадәтләре, йолалары, кием һәм ризыклары бар. Аларның һәрберсе – милләтләрне аерып торучы үзенчәлекле билгеләр. Бүгенге милләттәшләребезнең киенү культурасына тукталасым килә. Безнең татарларда милли киемнәргә игътибар җитеп бетәме? Әлбәттә, юк. Концертларга килгән тамашачылар арасында да, сәхнәдә чыгыш ясаучы артистлар арасында да милли кием кигәннәр бик сирәк. Бигрәк тә хатын-кызлар ярымшәрә чыгалар. Бу – битарафлыкмы, әллә сукырлыкмы? Газета-журнал битләрендә, телевизор экраннарында милли киемнәр күбрәк күрсәтелсә, яхшы булыр иде. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов татар морзалары кигән татар камзулын кия башлады. Карарга күңелле бит! Аннан үрнәк алып, башкалар да кия хәзер. Шулай дәвам итәргә кирәк. Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ. Казан

Ләйсән САФИНА әзерләде

25 март | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости
10.15 «Наше всё» 12+
11.05 «ПроУют» 0+
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «БЕРЕГИСЬ АВТОМОБИЛЯ» 12+
15.00 Праздничный концерт ко Дню Росгвардии 12+
17.00 «Я люблю мою страну» 0+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Эксклюзив» 16+
19.10 «Михаил Задорнов: вся жизнь» 16+
20.05 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.00 «НЕ ХОРОНИТЕ МЕНЯ БЕЗ ИВАНА» 16+
02.30 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Вести. Местное время
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.50 «В кругу друзей»
12.50 «Доктор Мясников» 12+
14.50 «Парад юмора» 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «МУЖ НА ПОЛТОРА ЧАСА» 16+
00.35 «Я ТОЖЕ ЕГО ЛЮБЛЮ» 12+
04.00 «КРУЖЕВА» 12+

МАТЧ ТВ

07.00, 08.30, 13.10, 16.30, 19.30, 03.55 Новости 0+
07.05, 13.15, 16.35, 19.35, 22.30, 00.45 Все на Матч!
08.35 Биатлон. Альфа-Банк Чемпионат России
13.55, 01.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
14.25, 22.40 Футбол. Чемпионат Италии
17.15 Футбол. МИР РПЛ. «Балтика» – «Пари НН»
20.25 Футбол. Чемпионат Германии
02.00 Мини-футбол. Чемпионат России. ПАРИ-Суперлига. «Синара» – «Тюмень» 0+
04.00 «Конор Макгрегор – ирландец» 12+
05.00 Смешанные единоборства. UFC

НТВ

04.45 «БЛИЗНЕЦ» 12+
06.25 «Жди меня» 12+
07.25 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 16+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Секрет на миллион» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
19.00 «Центральное телевидение»
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Звезды» 16+
23.00 «Международная пилорама» 18+
23.45 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
00.25 «Квартирник НТВ у Маргулиса» 16+
01.55 «Дачный ответ» 0+
02.45 «ДОЗНАВАТЕЛЬ» 16+

ДОМАШНИЙ

09.40 «Уютное утро» 16+
10.10 «КОГДА ЛЮБОВЬ СОВСЕМ НЕ ЖДЁШЬ» 16+
14.40 «МЫ ЭХО ДРУГ ДРУГА» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК» 16+
23.15 «КОРОЛЕВА ПРИ ИСПОЛНЕНИИ» 16+
01.20 «НАПАРНИЦЫ» 16+
03.00 «Преступления страсти» 16+
06.15 «ЧУЖАЯ ДОЧЬ» 16+

ЗВЕЗДА

05.50 «КАРЬЕРА ДИМЫ ГОРИНА» 12+
07.55 «Морской бой». 6+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.20 «Специальный репортаж» 16+
09.30 «ДЕЛОВЫЕ ЛЮДИ» 12+
11.10 «Легенды музыки» 12+
11.40 «СССР. Знак качества» 12+
12.30 «Не факт!» 12+
13.15 «Легенды кино» 12+
14.00 «Главный день» 16+
14.50 «Время героев» 16+
15.10, 23.10 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШЕРЛОКА ХОЛМСА И ДОКТОРА ВАТСОНА» 12+
21.30 «Галерея звезд» 12+
02.10 «ОНА ВАС ЛЮБИТ» 12+
03.35 «АХ, ВОДЕВИЛЬ, ВОДЕВИЛЬ…» 12+
04.40 «Отечественное стрелковое оружие» 16+

31 март | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 00.45 «Гомер китабы» 12+
08.00, 13.00 «Адымнар» 16+
08.30 «Тамчы-шоу» 0+
09.00 «Сөенеч» 0+
09.05 «Әти һәм мин» 0+
09.30 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.00 «Кызган казан» 6+
10.30 «Тархан» 6+
11.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.30 «Погружение на 100» 12+
13.40 «Татар сүзе» 12+
14.00 «Созвездие – Йолдызлык-2024» 6+
15.00 Гала-концерт конкурса-фестиваля "Творчество мира и согласия – Иҗат аша тынычлык һәм бердәмлеккә" 12+
16.00 «Ком сәгате» 16+
17.00 «Видеоспорт» 16+
17.30 «Соотечественники» 16+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней» 16+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Профсоюз – союз сильных» 12+
20.45 «Батырлар» 6+
21.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
23.00 «ПОБЕГ ИЗ БРАКА» 16+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+
05.50 Татарстан хәбәрләре 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять»
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 «Кто мы татары?» 12+
08.00, 02.45 «Шаян хәлләр» 16+
09.00, 03.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00, 04.35 «Гаилә учагы» 16+
13.30 «Егет чак, җырлар чак» 16+
15.40 И.Юзеев. «Гашыйклар тавы». Чаллы татар дәүләт драма театры спектакле 16+
17.15, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05, 23.50 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.50 Мирсәет Сөнгатуллинның 70 яшьлек юбилей кичәсе 12+
01.05 «Манзара» 16+
03.15 «Әдәби хәзинә» 6+
05.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

06.00 Новости
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.00, 12.00 Новости
10.15 «Жизнь своих» 12+
11.05 «Повара на колесах» 12+
12.15 Ко дню рождения Первого канала 16+
15.00 «Фабрика звезд». 20 лет спустя» 12+
16.10 «Лучше всех!» 0+
18.00 «Вечерние новости
19.00 «Большая история» 16+
21.00 «Время»
23.00 «Что? Где? Когда?» 16+
00.10 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

06.10, 01.05 «НЕ В ПАРНЯХ СЧАСТЬЕ» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00 Вести
11.50 «Большие перемены»
12.50 «МОЙ ЛЮБИМЫЙ ДРУГ» 12+
17.50 «Песни от всей души» 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+

МАТЧ ТВ

08.00, 08.30, 03.55 Новости 0+
08.05, 13.35, 15.55, 18.30, 22.30, 00.45 Все на Матч!
08.35, 11.50 Биатлон. Альфа-Банк Чемпионат России 0+
11.20 Биатлон с Дмитрием Губерниевым
13.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. ЦСКА – «Локомотив-Кубань»
16.15 Футбол. МИР РПЛ. «Рубин» – «Ахмат»
19.00 Футбол. МИР РПЛ. «Локомотив» – «Краснодар»
21.30 После футбола с Георгием Черданцевым
23.00 Смешанные единоборства. UFC 16+
01.30 «Что за спорт?» 12+
02.00 Мини-футбол. Чемпионат России. ПАРИ-Суперлига. «Синара» – «Тюмень» 0+
04.00 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. ЦСКА – «Лада» 6+
05.30 «Формула-1. Гаснут огни» 12+

НТВ

04.45 «БЛИЗНЕЦ» 12+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
12.00 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды…» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Маска» 12+
00.00 «Звезды сошлись» 16+
01.35 «ДОЗНАВАТЕЛЬ» 16+

ДОМАШНИЙ

14.25 «Пять ужинов» 16+
14.40 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК 16+
23.00 «ВТОРАЯ ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ» 16+
02.40 «Преступления страсти» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ШЕЛ ЧЕТВЕРТЫЙ ГОД ВОЙНЫ…» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
11.10 «Легенды армии» 12+
12.00 «Моторы и колеса» 12+
12.50 «Война миров» 16+
13.40 «Код доступа» 12+
14.30 «Улика из прошлого» 16+
15.20 «Скрытые угрозы» 16+
16.10 «Секретные материалы» 16+
17.05 «Загадки века» 12+
18.00 Главное 16+
19.45 «Легенды советского сыска» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.55 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА…» 12+
01.20 «АДМИРАЛ УШАКОВ» 12+
03.05 «КОРАБЛИ ШТУРМУЮТ БАСТИОНЫ» 12+
04.40 «Часовые памяти» 16+

Сынамыш

Халык әйтсә…

22 март җылы булса, 40 көн җылы торыр, бу көн суык булса, 40 көнгә сузылган суыклар көт тә тор.

23 мартта ала карга томшыгын канат астына яшерсә, көннәр суыта.

24 мартта ала каргалар тавышланып йөрсә, һава торышы бозылачак.

25 мартта яңгыр яуса, арыш уңар.

26 мартта кара каргалар кичен җыелышып, тавыш бирсә, алдагы атна җылы булыр.

27 мартта кар кояш җылысыннан эресә, уңышлы ел көтелә, яңгыр явып эресә – корылык.

28 мартта акчарлаклар очып килсә, апрель җәй кебек булыр.

29 март нинди – апрель шундый була.

30 мартта торналар килсә, кинәт җылытачак. Гөрләвекләр агарга тотынса, ташу да озак көттермәс.

31 март кичендә йолдызлар гадәттәгедән ваграк күренсә – яңгырга. Кошлар ояларын көньякка үрсә, җәй салкын килер.

Белдерү

Диплом о среднем профессиональном образовании, выданный ГАПОУ «Казанский техникум народных художественных промыслов» от 30.06.2022 г. рег. № 660 на имя Мухутдиновой Дины Халилевны, в связи с утерей считать недействительным.

Сәрия
МИФТАХОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

МӘГАРИФКӘ ҖӘЛ ТҮГЕЛ

ПРЕЗИДЕНТ ЮЛЛАМАСЫ ЭЗЕННӘН

Сыйныф җитәкчеләренең акчасы арта, чыгарылыш укучылары БДИны кабат тапшырып карый алачак. Владимир Путин Федераль Җыенга Юлламасында мәгариф өлкәсендәге төп мәсьәләләргә тукталган иде. Алты ел эчендә илкүләм программалар ярдәмендә башлангыч мәктәптән алып вузга кадәргә барлык уку йортларын яңартырга җыеналар. Әлеге программалар ничек тормышка ашырылачак?

Ремонт

Президент Юлламада киләсе елдан балалар бакчаларын капиталь төзекләндерү программасы башланачагын әйтте. Әлеге биналарның күбесе совет чорында ук төзелгән. Шуңа күрә яңартмыйча булмый. Барлыгы 18,5 меңгә якын мәктәп ремонт көтә. 2030 елга кадәр илнең барлык төбәкләрендә дә әлеге проблеманы хәл итү күздә тотыла. Бакча һәм мәктәпләрне капиталь төзекләндерүгә 400 миллиард сумнан артык акча тотылачак.

Татарстан Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының матбугат үзәгеннән алынган мәгълүматларга караганда, быел «Мәгариф» илкүләм проекты, республика һәм федераль программалар кысасында 185 мәгариф объекты төзекләндереләчәк. Шул исәптән 51 мәктәп һәм 21 бакча.

Мәгариф һәм фән министрлыгында исә безгә быел республика программасы нигезендә 12 урта мәктәп, 32 мәктәп, 20 бакча, 94 мәктәп ашханәсе, 4 һөнәри уку йорты һәм техникумнарның 14 тулай торагы ремонтланачагын әйттеләр.

Әйтик, Кайбыч районының Кече Мәми мәктәбендә, Әлмәтнең 40 нчы, Чүпрәле районындагы «Кояшкай», «Ивушка» балалар бакчаларында, Актаныш районының Такталачык авылындагы сәламәтлеге чикле балалар өчен интернат-мәктәптә төзекләндерү эшләре планлаштырылган. Әлеге акча республика бюджетыннан тотылачак.

Кайбыч районында 15 мәктәп, 10 бакча исәпләнә. Моннан тыш, 8 мәктәпкәчә төркем эшли. Районда көллиятләр юк.

Район мәгариф бүлеге башлыгы Илмас Хәмидуллин белдергәнчә, районда мәгариф оешмаларының күбесе яңартылган, төзекләндерелмәгәннәре аз.

– Төзекләндерү программалары бик кирәк. Балаларга җиһазландырылган, шартлары булган мәктәпләрдә уку күңеллерәк бит. Мәктәпләребезнең күбесе шәһәрнекеннән яхшырак. Әмма утыз ел элек ремонт ясалганнары барыбер таушалып тора. Шуңа күрә аның системасын булдырырга кирәк. Бер мәртәбә ремонтлап онытырга түгел. Күпмедер вакыттан соң тагын төзекләндерелсә, яхшы булыр иде, – ди ул.

Азнакай районының Сарлы мәктәбе 2025/2026 уку елында федераль төзекләндерү программасына кертелгән. Бүген унбер еллык мәктәптә дүрт авылдан 49 бала белем ала.

– Мәктәптә ремонт соңгы тапкыр 2013 елда үтте. Әмма хәзер тагын кирәк. Балаларыбыз бар бит, Аллага шөкер. Укытучылар җитә, – ди мәктәп директоры вазыйфасын башкаручы Минзилә Мөхәммәдиева. – Мәктәбебез зур булгач, кышын җылылык җитеп бетми. Диварларга буяу тисә, матур бит. Авыл мәктәпләре дә шәһәрнекеннән ким булырга тиеш түгел. Белем сыйфаты буенча калышмыйбыз. Иң мөһиме, мәктәпләр бетмәсен.

БДИ

Чыгарылыш сыйныф укучыларына үз теләкләре буенча БДИдан бер фәнне яңадан тапшырып карау мөмкинлеген бирергә кирәк, диде Президент. Моны ул вузларда кабул итү кампаниясе башланганчы тапшырырга тәкъдим итте.

Укучылар арасында борчылу, каушау аркасында имтиханнарны уңышсыз биргән очраклар бар. Начар бирелгән имтихан ул – вузга юл ябык дигән сүз. Андыйлар сынауны бары бер елдан соң гына тапшыра ала. Владимир Путинның тәкъдимен укучылар да, әти-әниләр һәм укытучылар да бик сөенеп кабул итте. Чөнки бу карарны алар күптән көткән иде.

Рособрнадзор башлыгы Анзор Музаев белдергәнчә, июнь аенда бер фәннән бердәм дәүләт имтиханын кабат тапшырырга мөмкин. Вузга керү кампаниясе тәмамланганчы, укучылар яңа нәтиҗәгә өметләнә алачак. Тик шул ягы бар: имтиханны яңадан тапшырганнан соң, ике билгенең берсен сайлап булмаячак, чөнки беренче билге юкка чыгарыла.

Саба районының Тимершык мәктәбе укучысы Айлия Хаҗиева узган ел рус теле сынавыннан 100 балл җыйган иде. Бу уңайдан аның фикерен белештек.

– Минемчә, бу – мәктәп укучылары өчен яхшы мөмкинлек. Әгәр дә укучы берәр фәннән БДИны түбән баллга бирсә, ул тагын да тырышып әзерләнеп, имтиханны югарырак баллга бирә ала. Ягъни аның имтиханга әзерләнергә теләге туа. Шулай ук, имтиханны кабат биреп булачагын белгәнгә, стресс кичерми, нык борчылмый һәм БДИны куркыныч әйбер итеп кабул итми, – ди КФУ студенты Айлия.

Чирмешән районының Лашман мәктәбе директоры урынбасары, җәмгыять белеме укытучысы Илдар Мөбарәкшиннең фикере башкачарак.

– Тырышып укыган укучы сынауны беренче тапкырдан ук яхшы бирә. Икенче юлы нәтиҗәсе начаррак була дип саныйм. Бернича генә баллга югары булырга мөмкин анысы. Мәсьәләнең икенче ягы бар: беренче имтихан нәтиҗәсе юкка чыгарылачак, – ди ул.

Аның кызы Алия дә быел БДИ тапшырырга җыена. Теләге – журналист булу. «Узган ел Чирмешәндәге лицейга күчкән иде. Безнең мәктәптә начар булганга түгел, башка сәбәпләре бар. Тырышып укый. Җәмгыять белеменнән үзем дә булышам», – ди укытучы әти.

Акча

Президент 2024 елның 1 сентябреннән мәктәпләр, көллиятләрдә директорларның тәрбия эшләре буенча киңәшчеләренә ай саен 5 мең сум күләмендә яңа федераль түләү кертергә тәкъдим итте. Моңа кадәр андый нәрсә юк иде. Бу тәрбия эшен көчәйтергә һәм югары квалификацияле белгечләрне җәлеп итәргә булышачак.

Юлламада Владимир Путин, 1 марттан халык саны 100 меңнән артмаган кечкенә шәһәрләрдә һәм торак пунктларда урнашкан мәктәпләрдә һәм көллият-техникумнарда белем бирүче сыйныф җитәкчеләренә һәм төркем кураторларына гамәлдәге федераль түләүне ике тапкыр арттырып, 10 мең сумга җиткерергә кирәклеген дә әйтте.

Сан

2024 елның 1 мартына булган мәгълүматларга караганда, республикада 13137 сыйныф җитәкчесе әлеге түләүне алачак.

Хәйдәр Зәйнуллин Арча районының Кәче мәктәбендә берничә фәннән укыта. Моннан тыш, 7 нче сыйныф җитәкчесе дә әле ул. Укытудан тыш, башка вазыйфалары да җитәрлек.

– Акча арта дигәч, көтәбез инде. Сыйныф белән эшләү җайлы түгел. Аның җаваплылыгы күп. Сыйныфымда – 8 бала. Әгәр тагын да күбрәк булса, нишләр идек икән? Әти-әниләр, балалар белән дә аңлашып эшләргә кирәк бит. Моңа кадәр сыйныф җитәкчеләренә игътибар җитмәде. Биш мең сум түли башлагач кына, караш яхшырган кебек тоелды. Өстәмә ярдәм – сөенеч бит ул, – ди ул.

Кеше акчасын санарга ярамый. Әмма сорамыйча кала алмадык. 32 ел стажы булган Хәйдәр Зәйнуллин 30 мең сум хезмәт хакы ала. Билгеле, бу акчага гына тормыш алып барып булмый. Шуңа күрә башка эш тә табарга туры килә. Берничә мәгариф оешмасында шашка, шахмат түгәрәкләре дә алып бара ул.

– Эшкә йөрү өчен юл чыгымнарына 6 мең сум китә. Акчасы күп булмаса да, хезмәтемне яратам. Район мәктәпләрендәге балаларны шахмат, шашка ярышларына әзерлим. Әзерләгәч, нәтиҗәсен күрәсе килә. Күрсәткеч булсын өчен исә тырышып эшләргә кирәк. Менә шулай йомык система буенча әйләнеп йөрибез, – ди ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ДИН КУШКАНЧА

Әле моннан берничә дистә ел элек кенә хәләл дигәндә бары тик ризыкны гына күз алдына китерә идек. Баксаң, бу күпкә тирәнрәк, күпкә киңрәк төшенчә икән. Хәзер хәләл медицина, хәләл белем бирү, хәләл кием дизайннарын да аптырыйсы түгел. Шунысы да бар: хәләл юнәлеше мөселманнарга гына түгел, башка дин тарафдарлары өчен дә кызыклы. Хәләл – сыйфат билгесеме? Дин кушканча яшәү ничек була?

Төп шарт – алдашмау

Энҗе Хисамиева хәләл тәм-томнар пешереп сата. Биш вакыт намазын калдырмый, дин кушканча яши. «Бу миңа бәрәкәт китерә», – дип, ихластан куана ул.

– Мин үземә эшлим, Аллаһ кушканнарны да үти алам. Бу бит – искиткеч мөмкинлек! Хәзерге көндә намаз укучы кешегә эш табу, хәләл юнәлештә кәсеп итү мөмкинлекләре күп. Нәрсә соң ул хәләл? Хәләл ул – иң элек, алдамау, – ди Энҗе Хисамиева.

Тәм-том хәләл булсын өчен, «бисмилләһ» дип әйтү генә җитми, билгеле. Аның үз таләпләре бар, ди Энҗе.

– Тортларымның составына зур игътибар бирәм. Әйтик, «творожный сыр», каты сыр кулланабыз бит инде. Хәләл пешергән очракта аның «микробного происхождения» дигәненнән файдаланабыз. Шулай ук кармин дигән буяу кулланмыйбыз, ул хәләл түгел. Желатин, пектинның да хәләлен кушабыз. Гомумән, минемчә, ризыкны нәрсә кушып пешерүгә бик талымлы булырга кирәк. «Хәләл торт» дип язып кына эш бетми. Әйтик, тортка шәраб рәсемнәре ясамыйм, ямьсез саналган язулар язмыйм. Кондитер кибетләрендә сыйфатлы һәм арзанлы продукция бар. Халык, билгеле, арзанлысына кызыга. Әмма сыйфат булсын өчен, бәягә дә риза булырга кирәк. Шөкер, минем тәм-томнарны сатып алучылар моны аңлыйлар. Мин кайчагында бизәү, язу өчен яисә тәм-томнарның граммнары артып китсә, өстәмә акча алмыйм, – ди Энҗе.

Хәләл яшәү – «кайф»

Мәҗлесләр алып баручы Рамил Шәрәфиев әнә шулай ди.

– Хәләл яшәү рәвеше аны даими алып барганда ләззәт китерә. Бүген намаз укыдым һәм хәләл ашадым да иртәгә тормышымны элеккечә дәвам иттерәм дип уйларга ярамый. Аллаһы Тәгалә да даимилекне сөя, – ди Рамил. – Әйе, күп кеше «картайгач намаз укырмын», фәлән-фәлән дип сәбәпләрен табарга тырыша. Үзебезнең дә аклану шундыйрак иде. Әмма хәләл тормыш юлына аяк баскач, намаз укый башлагач, Аллаһы Тәгалә үзе җиңеллек бирә, юлларын ача икән. Хәләл акча эшләү мөмкинлекләре дә җитәрлек. «Вакыт юк», «авыр» диючеләр – үзләрендә көч таба алмаучылар гына.

Рамил әйтүенчә, хәләл яшәү рәвеше модага да әйләнеп бара һәм бу сөендерә.

– Хәләл ул – иң элек, ризык, якыннар белән аралашу. Әле күптән түгел генә шуңа бәйле вәгазь тыңладым. Хәләл аралашу – кешене рәнҗетмәү, аның хакына кермәү ул. Безнең бигрәк тә әти-әни белән аралашу хәләл булырга тиеш, – ди ул. – Казанда хәләл юнәлештә нидер эшләү бик җайлы. Адым саен хәләл туклану урыннары бар, кием-салымнарыбыз да тыйнакланды. Кызларның лак белән тырнак буяулары да кимеде.

Рамил хәзер хәләл мәҗлесләр генә алып бара. Моның шартлары нинди?

– «Хәләл мәҗлес» төшенчәсенең мәгънәсе киң. Беренчедән, өстәлдәге ризык хәләл булырга, табында исерткеч булмаска тиеш. Шулай ук мәҗлестә музыка да булырга тиеш түгел. Ир-ат белән хатын-кызлар аерым утырса хәерле, – дип аңлатты алып баручы. – Без исә әлегә күбрәк хәмерсез мәҗлесләр алып барабыз. Ләкин инде, шөкер, тулаем шәригатькә туры килерлек мәҗлесләр уздыручылар да арта. Монда инде бәйрәм күбрәк аралашуга корыла.

Хәләл матурлык

Энҗе Билалова гүзәл затларга хәләл ысул белән каш ясый.

– Хәләлнең бары тик уңай, ә хәрамның тискәре икәнен аңлаган хәлдә хәләл тормыш рәвеше алып бару кыен түгел. Кешенең һәрвакыт бу ике нәрсә арасында сайлау ирегә бар. Бу мөселман өчен үзенең мәңгелек яшәү урыны итеп җәннәтне яисә җәһәннәмне сайлавына тиң. Җәһәннәмгә ни буласын белгәч, әлбәттә, хәрамга якын да киләсе килми, – ди Энҗе.

> **Хәләл турында миф һәм чынбарлык**
>
> | | |
> |---|---|
> | Дуңгыз ите түгел, димәк, хәләл! | Мөселманга шәригать буенча чалынмаган теләсә кайсы малның итен ашау рөхсәт ителми |
> | Ризыкка «бисмилләһ» дисәң, ул хәләл була | Хәләл булмаган ризыкка «бисмилләһ» дию аны хәләл ясамый. Әлбәттә, «бисмилләһ» сүзен ашар алдыннан әйтергә кирәк, әмма азык-төлекнең хәләллеген ризык табынга килгәнче үк кайгырту мөһим |
> | «Мөселман», «татар», «көнчыгыш» сүзләре язылган ризык – хәләл | Этикеткада андый сүзләрне еш күрәбез. Әмма хәләллекне бу гына раслый алмый. Еш кына мондый сүзләр куллану – бары тик оста маркетинг алымы |
> | Авылдан килгән ит хәләл була | Бу – бик наив ышану. Малның нинди шартларда үсүе, нәрсә ашавы, ничек чалынуын белергә кирәк |

kazanforum.ru/riamediabank.ru

> ## *Halal Life Style ул –...*
>
> *Россия территориясендә 20 миллионнан артык мөселман яши, алар хәләл мәгариф, медицина, туризмга мохтаҗ. Бүген бик кирәкле юнәлеш.*
>
> Рөстәм МИҢНЕХАНОВ,
> Татарстан Рәисе
>
> *Хәләл ул әле казылык кына түгел. Мөселман бу дөньяга килгән икән, аның хәләл балалар бакчасы да, хәләл мәктәбе дә булырга тиеш. Бишектән алып кабергә кадәр без мөселманга уңайлы мохиттә яшәү мөмкинлеге тудырырга тиеш.*
>
> Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,
> Татарстан мөфтие
>
> *Хәзерге вакытта «хәләл» – ислам динен тотучыларның стандартлары гына түгел, ә продукциянең һәм күрсәтелә торган хезмәтнең сыйфат билгесе дә. Без хәзер бу юнәлешне үстерүгә бер адым ясыйбыз, Татарстан һәм ил халкын хәләл тормыш рәвешенә ияләштерәбез, безгә килүче мөселман туристлар санын арттырабыз, хәләл брендларны популярлаштырабыз.*
>
> Талия МИҢНУЛЛИНА,
> Татарстанның Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе

Хәләл ысул белән каш ясау нидән гыйбарәт соң? Энҗе сүзләренчә, ислам динендә каш йолку тыела. «Әмма мөселман хатын-кызларының да матур кашлы буласы килә бит. Без төп каш формасыннан читкә чыгып торучы артык бөртекләргә махсус катнашма ярдәмендә аксыл төс кертәбез. Хәләл сертификатлары булган составлар белән генә эшлим. Ягъни су үткәрә торган. Бу тәһарәт алу өчен бик мөһим», – дип аңлатты ул.

Энҗе дә бүген «хәләл» төшенчәсе модада дигән фикердә. «Әмма чын мөселман өчен «хәләл» төшенчәсе «мода» төшенчәсеннән күпкә киңрәк мәгънәгә ия. Мода үзгәрә, ә хәләл гомерлек. Ул – мөселманның асылы», – ди Энҗе.

Гомумән, матурлык индустриясендә хәләл ныклап тамыр җәеп бара, дисәк ялгышмабыз. Әйтик, хәләл ысул белән эпиляция ясау, хәләл массаж студияләре дә, фитнес-заллар да юк түгел.

Хәләл бизнес

Кайбыч районының Кошман авылында яшәүче Рушан Сайрановка бу сүз чит түгел. Ул экологик чиста һәм хәләл тавыклар (димәк, антибиотик, укол, гормоннарсыз) үстерә, хәләл тормыш рәвеше алып бара.

– Халыкта хәләл юнәлешкә карашлар төрле, хәзер бу тармакта төрлелек күп: хәләл коучлар да, хәләл тамадалар да, башкасы да бар, – ди ул. – Ислам финанслары ныклап торып эшләп китсен иде дип телим. Бу бик кирәк.

Рушан Сайранов сүзләренчә, хәләл бизнес алып барганда кредит алмаска тырышу, килешүләрне үтәү, сыйфатлы продукция куллану һәм җитештерү, чисталык, пөхтәлек таләпләре өстенлек итә.

Анынча, хәләл тормыш итү җиңел. Әмма читтән караучыларга алай тоелмаска мөмкин.

– Без үз юлыбызда Аллаһы Тәгаләдән җиңеллек сорыйбыз. Сүз дә юк, кырыйдан караганда, болай яшәү кыенрактыр. Чөнки билгеле бер чикләүләр дә бар. Әмма бездә җәмгыять шундый, шуңа күрә кайбер очракта аңлашылмаучанлыклар килеп чыга. Тик ул каршылыклар уңай якка үзгәрә. Аллаһы Тәгалә кушкан юл шул, син ул законнарга каршы килә алмыйсың, – ди Рушан.

РӘШИТ КЕБЕКЛӘР ЮКТЫР

Казанда яшәүче Рәшит Хәсәнов турында язуыбызны сорап, безгә аның күршесе мөрәҗәгать итте. Халидә Баһаутдинова башта «ВТ»ның социаль челтәрдәге төркеменә язды, аннары редакциягә үзе килде. «Безнең Рәшит кебек көчле рухлы, сынауларны җиңеп яшәүче егетне башкалар да белсен әле», – ди ул.

– Без Казанның Яңа бистәсендә күршеләр булып яшәдек. Рәшитнең әнисе Хава апа, аның ире, әнисе, апасы белән җизнәсе, ике баласы бер йортта дус-тату яшәүләре белән күңелгә кереп калдылар. Барысын да бер кечкенә генә агач йорт сыйдырыр иде. Хава апа бик укымышлы кеше иде. Пенсиягә чыккач та эшен ташламады, балалар укытып йөрде әле, – дип искә ала Халидә апа. – Хава апаның ике баласы – Рәшит белән Рәмзия музыка мәктәбендә дә укып йөрделәр. Бервакыт гыйнвар аенда Рәшит укырга киткән. Ул көнне салкын булгач, балаларны укытып тормаганнар. Шуннан соң Рәшит музыка мәктәбенә юл тоткан. Тик анда да барып җитмәгән, бәлагә тарыган иде. Рәшит трамвай астына эләгә. Заманалар авыр чак. Медицинаның да хәзерге кебек көчле вакыты түгел. Ул чакта Рәшит өчен бөтен урамыбыз белән кайгырдык.

Халидә апа сөйләвенчә, кечкенә Рәшитне сүтеп җыялар. Ул чакларда әнисе ниләр кичергәнен үзе генә белә торгандыр. Әмма бирешми, зарланмый. Баласы хакына барысын да эшли. Йокысыз төннәр, гел җылы сүз әйтеп юату… Никадәр генә тырышсалар да, табиблар Рәшитнең аягын саклап кала алмыйлар. Ике аягын да тездән югары кисәләр.

– Рәшит фаҗигагә юлыккач, аларга шәһәр үзәгеннән бар уңайлыклары булган фатир бирделәр. Юллар аерылса да, аралашуыбызны дәвам иттек без. Бик якын кешеләргә әйләнгән идек инде, – ди Халидә апа. – Йөгереп йөргән бала өчен бер мәлдә аяксыз калу бик читен була. Әле бит юатыр сүзе дә кирәк. Хәзерге кебек психологлар да юк. Барысына бер Хава апа.

Рәшит үзе дә үҗәт егет булып чыга. Урында яткан килеш китап укуын дәвам иттерә. Протез аяклар белән яңадан йөрергә өйрәнә. Протезлары да бик авыр була. Әмма аяклы булу теләге үзенекен эшли – өйрәнә. Мәктәпне яхшы билгеләргә тәмамлап, югары уку йортына керә. Аны тәмамлагач, юллама буенча Вологда шәһәренә җибәрәләр.

Язмыш Рәшит абыйны шунда булачак хатыны белән очраштыра. Оля исемле кызга ул бер күрүдә гашыйк була. Әле яңа гына мәктәп тәмамлаган кыз булса да, үз яшенә күрә бик акыллы була ул. Казанга икәү бергә кайталар. Өйләнешкәч, Оля югары уку йортына укырга керә. Рәшит гаиләсе дә үз итә кызны. Бер оягa барысы да сыя. Озакламый аларның уллары Илдар туа. Хәзер инде Илдар үзе ике малай үстерә.

– Хава апабыз арабызда юк инде. Инде Рәшит тә 70 яшьтә. Гомере буе үзе укыган кафедрада эшләде. Күпләр аның ике аягын югалтканын белмәде дә. Ничек итсә итте, протез аякларга ияләшеп, башкалардан ким-хур яшәмәде, – ди Халидә апа. – Рәшитнең тылы нык булды аның. Олясының мәхәббәте дә булышты. Әгәр аның урынында башка берәү булса, бәлки, арып та китәр иде, тормышлары да башкача юл алыр иде.

Рәшит абыйны гомер көзендә тагын сынау көтеп тора. Ул инсульт кичерә. Инде хәзер йөри дә алмый, урында гына ята икән. Ә бит сөйгән ярлар да, ир белән хатын да тормыш авырлыгында сынала.



Рәшит абыйга Олясы гомер буе терәк була.

– Бу гаиләгә карап, гомер буе сокландык. Оляны мин Фәнис Яруллинның хатыны Нурсөя ханыма тиңләр идем. Хәзер бит авыру ирне түгел, сау-сәламәтен дә санлап яшәүче сирәк. Яшьләр башкача уйлый, тиз хәл итә, – ди Халидә апа. – Сынауларны бергә күтәргәндә генә аны җиңел узып була. Борчу-хәсрәтләр килгәндә күңелне төшермик, язмыш сынауларына бирешмәгән кешеләрне уйлап, алардан үрнәк алыйк.

genproc.gov.ru

БЕР ГАИЛӘДӘН – ӨЧ МӘЕТ

АЛАБУГАДА ГАЗ ШАРТЛАП, ИКЕ БАЛА ҺӘМ ӘТИЛӘРЕ ҮЛДЕ

15 март төнендә килеп чыккан янгында Алабуга районының Гринландия поселогында урнашкан Гатауллиннар йортында берьюлы ике бала вафат булды. Коткаручылар башта тәрбиягә алынган 12 яшьлек Настяның гәүдәсен таптылар. Соңрак 3 яшьлек Артурның (кече улларының да исеме әтисенеке кебек) мәете табылды. Тәненең 90 проценты пешкән Артур 19 март иртәсендә хастаханәдә вафат булды. Гаилә башлыгы Артур 8 яшьлек уллары Тамерланны өйдән алып чыга алган. Калган балаларны алырга кереп киткәч, бик каты пешә ул…

Фаҗига булган көнне Артур өйдә өч баласы белән кала. Хатыны Тамара уртанчы уллары Алмаз белән Түбән Новгородка бәйгегә киткән була. Булган хәлләрне шундук Тамарага җиткерәләр. Алар барып та җитә алмыйлар, кире кайтырга чыгалар. Тамараның үз хәле дә җиңелләрдән түгел. Газиз баласын, үз кызыдай якын күргән Настяны югалту ачысы әле йөрәкнең түрендә торган мәлдә, савыгыр, бирешмәс, гаиләсе янына кайтыр дип өметләнгән Артур да якты дөньядан китеп барды. Аны 19 мартта җирләделәр.

– Бик авыр хәлдә без. Моны сүзләр белән аңлатып булмый. Апабыз ничек түзәдер, үз хәлен үзе генә белә ул, – диде Тамараның сеңлесе Диана Карманова. – Апам белән җизни бик матур яшәделәр. Тормышлары түгәрәк иде. Өч уллары туды. Яңа бистәдә йорт салып чыкканнар иде. Тик, кызганыч, матур итеп гомер итәргә язмаган икән.

Бу гаиләгә 2023 елның җәендә килеп кереп, җылы оя тапкан Настя алар белән бары тик ярты ел гына яшәп кала. Кызчык өйгә килеп керүгә, беренче көннән аларга «әти», «әни» дип дәшә. Аның да янгында һәлак булуын газетабыз белән даими элемтәдә торган волонтерлар җиткерде.

– Настяны бик ярата идек без. Үзе дә бик тыйнак, кешеләр ярата торган бала булды. Кызганыч, үз әнисе тормышта башка юлны сайлаган иде аның. Абыйсы, апасы бар иде. Абыйсы да исән түгел инде. Махсус хәрби операция башланганда ул төрмәдә иде. Тизрәк өемә кайтырмын дип, үзе теләп СВОга китә. Шунда гомере өзелә. Әниләре авырый хәзер. Урында гына ята, – ди бу гаиләнең танышы Алинә Гатина.

Настяның Виктория исемле апасы да бар. Сеңелләрен тәрбиягә алган гаиләгә ул да килеп йөри башлый. Килә генәме соң, күңеленә тынычлык тапкан җиргә тиз ияләшә. Мамадышта белем ала, атна саен Гатауллиннарга кайтып йөри. Сеңлесе янында була.

– Настяны да, Виканы да бик якын итә идек. Без – зур гаилә. Күңелебездә һәркемгә урын бар. Әниебез барыбызга да терәк. Авыр чакта да ул янәшәдә. Бар туганнарыбыз Тамарабыз янында хәзер. Бу ачы хәсрәтне ничек җиңә алырбыз, белмим, – ди Диана. – Гаиләбезгә ярдәм кулы сузган һәркемгә чиксез рәхмәтлебез. Берәүгә дә мондый хәлдә калырга язмасын.

Алабуга хакимиятеннән хәбәр итүләренчә, Гатауллиннар гаиләсенә яшәр өчен өч бүлмәле фатир биреләчәк. Шулай ук үлгәннәрне җирләү өчен дә матди ярдәм каралган.

Мәрхәмәтле кешеләр исә бу гаиләгә булышуын дәвам иттерә. Беренче көннәрдән үк акча күчерәләр. 1 миллион сумнан артык акча җыелган инде.

Тамара Гатауллина исемендәге «Ак Барс», «Уралсиб» һәм «Альфа-Банк» карталары 8-917-393-29-64 телефон номерына беркетелгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

Озакламый Буа театры җитәкчесе Раил САДРИЕВны ил геройларының берсе итеп тәкъдим итәчәкләр. Сүз Константин Богомоловның «Голоса страны» («Ил авазы») авторлык проекты турында бара. Ул эш-гамәлләре белән тормышны яхшы якка үзгәрткән төрле һөнәр ияләре, гади кешеләр турында 12 документаль моноспектакльдән гыйбарәт. Әлеге спектакльләр ВДНХда «Россия» халыкара күргәзмә-форумында күрсәтеләчәк.

Чулпан Гарифуллина

РАИЛ САДРИЕВ: «КӨЗГЕГӘ КАРАГАЧ, МИН БҮТӘН РАИЛНЕ КҮРӘМ»

Раил Садриевны герой буларак ачкан спектакль «Медитативный еж» дип атала. Ул нинди эш-гамәлләре белән мондый игътибарга лаек булган, гомумән, кемнәр алар хәзерге заман геройлары – шул хакта сөйләштек.

:: Проект герое булыр өчен нинди сыйфатлар кирәк?

– Белмим инде, нинди тәгълиматка таянып эш иткәннәрдер. Гади тормыштан алынган 12 герой, аларны танылган артистлар уйнаячак. Башта мин, әллә уйнарга чакыралармы икән, дип шатландым. Ә алар геройларның берсе – сез, диләр. Алдан бу миңа сәер булып тоелды. Без мәктәптә укыганда, геройлар башка кешеләр иде. Яшь геройлар – Валя Котик, Леня Голиковлар тәэсирендә үстек. Безнең авылның үз геройлары да бар иде. Сания апа – Александра Николаева, мәсәлән. Менә хәзер тарихи герой, авылдаш, күршем, туганым Гомәр Толымбайның тормышын, иҗатын өйрәнәбез. Аның истәлегенә авылда бюст куярга җыенабыз. Милләт өчен гомерләрен фида кылган Әхмәр хәзрәт, Нургали Хәсәновларны да искә алабыз. Минем өчен геройлар – менә шундый шәхесләр. Инде хәзер үзеңне герой дип әйткәч, алар янына үзеңне куеп буламы, дип уйга калдым. Чөнки көзгегә карагач, мин бүтән Раилне күрәм. Сез бер Раилне күрсәгез, мин бүтәнен беләм. Кайчак 50–60 ел бергә торган парлар да бер-берсен белеп бетерә алмый. Кешенең беркемгә дә күрсәтмәгән «файл»лары шактый аның. Аларны халыкка чыгарырга ярамый да. Әйтәм бит, кешелек әле «чистарыну» чорына кереп кенә бара. Без үзгәрештә һәм мин үземне шушы үзгәреш вакытына тәңгәл килә, тоеп-сизеп яши һәм алга бара торган кеше дип саныйм. Бәлкем, кайбер фикерләр тәңгәл килгәнгә күрә, мине герой итеп алганнардыр, дип уйлыйм.

:: Документаль спектакльнең авторы һәм куючы режиссеры сине яхшы белгән кешеләр булса кирәк.

– Пьеса авторы – Илгиз Зәйни, режиссеры – Айдар Җаббаров. Ә мине уйнаучы актер – Чехов театрыннан Александр Семчев. Аны миңа охшамаган, 100 килога ябыккан булса да юан, синең энергетиканы, дуамаллыкны бирә алырмы икән, диләр. Бу очракта Айдар мине белә, аңа таянам. Пьесаны укыдым, анда бер ялган юк. Ул бит ничек булды: минем турында мәгълүматны тапканнар, аннары Буага кайтып, документаль фильм төшерделәр, аннары килешү җибәрделәр, аннары инде фотограф белән кайттылар. Шуннан соң гына Илгиз Зәйни шул фильм-интервью нигезендә пьеса язды. Үзеңне сәхнәдән карау ничектер инде, белмим дә. Бу хәлләрне читтән күзәтеп йөргән хатын: «Син Ленин сыман», – ди беркөнне. «Ник алай?» – мин әйтәм. «Ленинны да театрда уйныйлар иде, сине дә», – ди.

:: Театр директорлары арасында герой – син беренчедер.

– Аның проекты да яңалык бит. Кайчан әле көндәлек тормыштагы кешеләрне герой итеп танытырлар иде? Анда бит 68 яшьлек эшлекле аралашу эксперты, пластик хирург, механик, океанолог – тагын әллә кемнәр бар. Ә икенче яктан карасаң, бу – совет чорында булган нәрсәләргә кире кайту. Кирәкле эш дип саныйм. Көндәлек тормышта бизнесменнар, Филипп Киркоровлар гына герой түгел. Киресенчә, антигерой әле алар. Алайса бит җыен бозыклык герой булды, чын кешеләр күләгәдә калды. Мин әйтмим инде, без – чын геройлар, дип. Айдар җырлый бит әле: «Әллә кем түгел без», – дип, әмма ким түгел, бәлкем, чорына туры килә торган геройлардыр без. Туксанынчы елларны үткән, күрәсен күргән... Яшисен яшәгән дип тә әйтер идем, тагын яшисе килә әле. Эшлисе эшләр күп чөнки.

> Мин – дөнья яхшыланды, яшисе иде дип утыра торган кеше түгел, эшлисе эшләр күп дип яши торган кеше. Шуңа күрә вакыт та, көн дә җитми.

:: Театр Буаны ничек үзгәртте?

– Үзгәртте һәм үзгәртә. Халык өчен театрга йөрү гадәти күренешкә әйләнеп бара. Безгә буалар гына түгел, Апас, Тәтеш, Казаннан билет алып килүчеләр дә бар. Чувашиядән дә киләләр. Бинаның проекты да бик матур, килешле. Аны хәзер тулыландырырга, җанландырырга

«Кодалар-кодачалар»

«Шобага»

«Безнең өй өянкеләр астында иде...»

кирәк. Элек стационарда ике-өч спектакль уйнап, калган вакытны гастрольдә үткәрсәк, хәзер монда унны уйнарга кирәк. Әлегә айга биш спектакль уйныйбыз. Моннан тыш безнеке булмаган чаралар да бар. Әйтик, бездә Камал, Курчак, Бөгелмә, Чабаксар яшь тамашачы театрлары гастрольләре булачак. Аннан соң эстрада концертлары да шактый. «Йолдызлык» концерты үтте, 27 мартта «Тантана» театр фестивале бездә узачак.

:: Камал театры, мәсәлән, сәхнәгә эстрада концертларын кертергә атлыгып тормый, энергетика үзгәрә, ди. Син дә энергетикага игътибарлы кеше юкса.

– Камал театрының сайланырга мөмкинлеге бар. Без исә кертмичә булдыра алмыйбыз. Салаватны да, Илсөяне дә, Тямаевны да күтәп алабыз. Бу – Буадагы иң зур заллы бердәнбер бина. Казанда исә андый заллар бихисап. Ә энергетикага килгәндә, безгә килеп кергән кеше үзе үзгәрә. Безнең үз кагыйдәләребез бар. Һәр нәрсәнең – үз тәртибе, үз җае.

:: Нинди тәртип, кагыйдәләрегез бар?

– Әлеге дә баягы татарлык традициясе. Килгән артистларга чәй куелган, табын корылган. Бинадагы һәр кеше, идән юучыдан алып артистка кадәр елмаеп исәнләшергә тиеш. Бу да – язылмаган кагыйдә. Кабул итүче як эчке җылылыгы белән бүлешергә тиеш. Без үзебез гел юлда һәм бу нәрсәнең күп җирдә булмавын күрәбез. Татар дөньясында ул бар әле, чыккач, югала. Без сезгә бернәрсә дә тиеш түгел, дигән караш инде бу. Алай ярамый. Ул театр йөзен генә түгел, шул җирлекнең йөзен җимерә. Һәр җирдә кешелеклелек булсын. Кеше синдә үз чагылышын күрсен.

> Тәнкыйтьне беркем дә яратмый. Ләкин бит ул – кылган гамәлеңнең үзеңә әйләнеп кайтуы. Арт шәрифеңне күрмисең икән, хәзер тәнкыйть очып киләчәк һәм күрсәтәчәк. Аны төрлечә кабул итеп була. Монда нәрсәдер бар, әмма син әйткәнчә үк түгел дип кабул итү – иң яхшысы.

:: Үзеңне еш тәнкыйтьлиләрме?

– Ничек кенә! Әле мин белмәгәне күпмедер. Буа театры яңа бинaлы булгач, дошманнарым да бермә-бер артты. Аны миңа Әлмәт театры директоры Фәридә Исмәгыйлова әйтте. «Котлыйм, дошманнарың бермә-бер артты», – диде. «Шуның берсе син түгелдер бит, Фәридә Бәгыйсовна?» – дидем. Була торган хәл. Минем үземнең бер дошманым да юк. Коллегалар арасында дошман күрүчеләр бардыр, аларны да аңлыйм. Алар бит минем эчтә нинди завод эшләп торганын белми. Анда һәр нәрсә анализлана. Минем өчен хата, уй кебек үк – иң зур коралларның берсе. Кабатланмаган очракта. Хата кабатланса, ул инде гөнаһка әйләнә, ул сине боза.

:: Театрларда, гомумән, зур коллективларда төркемнәргә бүленү күренеше бар. Хезмәттәшләрне ничек бер йодрыкка туплап тотарга?

– Кайбер түрәләр, ник үзең генә мәйданда, ник башкаларга юл куймыйсың, дип әйтәләр. Бездә 2019 елдан башлап 6 кеше мактаулы исемгә ия булды. Ә бит коллективның 70 проценты – урамнан кергән кешеләр. Буага кайтырга теләгән артистларның соңгы 5–6 елда булганы юк. Гәрчә ел саен театр училищесына автобус җибәрәм, имтихан спектакльләрен бирeдә уйнарга мөмкинлек бирәм, бүләкләр өләшәм. Ел саен диплом спектакльләрен карарга йөрим. Былтыр, башка килмим, дип әйтеп кайттым. Булмый, анда безгә яраклы артистлар юк, күрәсең.

Бүген 20 артистым бар, мин аларны спецназ дип йөртәм. Безнең кебек гастрольдә йөрүче бер театр юк. Февральдә генә дә 20 көн Башкортстанда булдык һәм ярты еллык планны үтәп кайттык. Шушы вакыт аралыгында 38 спектакль уйнадык, аның 18е Пушкин картасы буенча иде. Бу артистлар декорацияне дә үзе кора, үзе сүтә, бөтен эшне дә үзе башкара. Автобус шоферлары да артист бездә. Без читтә популяр, заллар тулы. Хәзер шул тонусны тотып торырга кирәк. Ә эчтә коллективны тотып торуның үз җае бар. Бу җәһәттән дә мине диктаторлыкта гаеплиләр. Алай түгел. Бездә – тәртип, ул читтә бигрәк тә сизелә. Ә берәрсенең группировкалар оештырырга маташуын күрәм икән, нинди генә талантлы булмасын, саубуллашам. Чөнки ул – метастаза. Берничә тапкыр шулай эшләгән булды.

:: Артык игътибар бозмыймы?

– Бер түрәнең, йолдыз булудан тукта инде, дип әйткәне бар. Мин йолдызмыни? Минем бит үз машинам да юк! Артистлар белән бер автобуста йөрим, алар белән шунда йоклыйм, ашыйм, эчәм. Алар белән бергә декорация ташыйм. Эш-гамәлләреңне даими анализласаң, кылган хаталарың өчен вакытында гафу үтенә белсәң, бозылмыйсың. Әле кичә генә бер кешегә кызып китеп акырган идем, бүген гафу үтендем. «Кызып кителгән, гафу ит, яме», – дидем. Конфликт бетте. «Обнуление» – шәп нәрсә ул.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА



«Виктория»



«Дәрвиш»

ВТ
2024 гаилә елы
И туган тел, и матур тел...

«Җылы оя»

БӘЙГЕ

50000 сум күләмендә 6 премия!

Гаилә ул – безнең оя. Ул – безнең тамырыбыз, канатыбыз, тормыш нигезе.
Ныклы дәүләт исә ныклы гаиләләрдән җыела. «Ватаным Татарстан» газетасы Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе белән берлектә күркәм гаиләләрне барлау, җәмгыятьтә ата-ана абруен арттыру максатыннан, «Җылы оя» дигән зур бәйге игълан итә!
Матур, дус, тату гаилә сере нидә? Бала тәрбияләүдә нәрсә мөһим? Гаиләдә тел, милли үзенчәлек саклансын өчен нишләргә? Әлеге сорауларга ачыклык керткән үрнәк татар, чуаш, мари, мордва, удмурт гаиләләре турында язмаларыгызны көтеп калабыз, кадерле укучылар! Бәйге таләпләренә туры килгән язмалар «Ватаным Татарстан» газетасында һәм vatantat.ru сайтында басылып барачак. Җиңүчеләр декабрь аенда билгеле булачак һәм тантаналы шартларда бүләкләнәчәк.

БӘЙГЕ НОМИНАЦИЯЛӘРЕ

«КҮРКӘМ ГАИЛӘ»

Гаилә, гаилә кыйммәтләре, милли гореф-гадәтләр, көндәлек тормышта туган телнең роле турында иң яхшы язма.

I урын – 50000 сум
II урын – 30000 сум
III урын – 20000 сум

Татарстанда яшәүче чуаш, мари, мордва, удмурт гаиләләре турында иң яхшы язма – 50000 сум (II, III урыннар каралмаган)

«ИШЛЕ БӘХЕТ»

Күпбалалы гаиләләр, шул исәптән тәрбиягә балалар алган гаиләләр, гаилә кыйммәтләре, милли гореф-гадәтләр, көндәлек тормышта туган телнең роле һәм милли кыйммәтләрне, туган телне буыннан-буынга күчерү әһәмияте турында иң яхшы язма.

I урын – 50000 сум
II урын – 30000 сум
III урын – 20000 сум

Татарстанда яшәүче чуаш, мари, мордва, удмурт гаиләләре турында иң яхшы язма – 50000 сум (II, III урыннар каралмаган)

«БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК…»

8–11 нче сыйныф укучыларыннан үз гаиләләре турында иң яхшы язма.

I урын – 50000 сум
II урын – 30000 сум
III урын – 20000 сум

Татарстанда яшәүче чуаш, мари, мордва, удмурт гаиләләре турында иң яхшы язма – 50000 сум (II, III урыннар каралмаган)

БӘЙГЕНЕҢ ШАРТЛАРЫ

- **«Җылы оя»** бәйгесенә язмалар **2024 елның 1 мартыннан 2024 елның 1 ноябренә кадәр кабул ителә.** Нигезләмә белән **www.vatantat.ru** сайтында танышырга мөмкин.
- Бәйгегә шигырь, поэма, хикәя-повестьлар, башка матбугат чараларында басылган язмалар кабул ителми. Язма күләме басма форматта, Times New Roman шрифты, 1,5 юл арасы белән 3 биттән артмаска тиеш. Материаллар **420097, Казан, Академия урамы, 2 нче йорт** адресына яки **konkurs_vt@mail.ru** электрон почтасына кабул ителә һәм кире кайтарылмый. Хатта авторның исем-фамилиясе, яше, торган урыны күрсәтелергә тиеш. Белешмә өчен телефон: **8(843) 222 09 70, 8917 927 00 40.**
- Бәйгедә катнашучының 2024 елның беренче яки икенче яртыеллыгына (кимендә алты айга) «Ватаным Татарстан» газетасына язылган булуы шарт, квитанция редакциягә язма белән бергә җибәрелә. (Исегезгә төшерәбез: һәр айның 15 нче числосына кадәр язылган очракта газета киләсе айдан килә башлый.)

Бәйгенең нигезләмәсе, тулырак мәгълүмат – **www.vatantat.ru** сайтында. Чара 2024 елның 1 мартыннан 2024 елның 30 декабренә кадәр дәвам итә. Оештыручысы – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. *Реклама* 12+

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70. E-mail: vtreklama@mail.ru



Сканворд җаваплары

Горизонталь: зөбәрҗәт, малтабар, җитез, кыен, пазл, орлык, калкан, Иоганн, ахыр, Рабит, йола, Люстра, латте, Ямаш, Краско, аш, Фоат, тир, Силк, гид, Штирлиц, шифа, Кави, Ирада, цена, ел, Ренат, Ту, Айтуганова, бимаза.

Вертикаль: Зиннуров, яла, Шарлама, Ашыт, ләхет, титр, кирле, ил, фри, әрҗә, Сяо, Цицерон, кабартма, реле, атсыз, нарат, шан, еланбаш, сида, ата, арзан, Рифә, ату, Кәтүк, Ла, рак, Лэйна, Сега, Аулак, Ив, рамазан, ординатура.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Әз-мәз мәзәк

– Син чәчәкләр яратасыңмы?
– Әйе.
– Мин – нарцисс.

***

Берәр кыйммәтле нәрсә сатып алсаң, гадәттә, бүләккә мондыйрак ташлама бирәләр: химчисткада смокинг чистартуга, еланнар ашавын сатып алуга, сулагайлар кибетенә, француз телен өйрәнүгә.

***

– Галия, эш көне тәмам, бар, өеңә кайт инде.
– Юк. Анда кайтсам, дәрес әзерлисе була.

***

– Син мине яратмыйсың бугай…
– Юкны сөйләмә, мин бөтен кешене яратмыйм.

***

Безнең эш графигы бик уңайлы, чөнки үзең сайлыйсың: атна уртасында калып эшлисеңме яки ял көне чыгасыңмы.

***

– Мин яшь чакта шундый җилбәзәк идем.
– Син хәзер дә яшь күренәсең.

***

Австралиядә юлыңа кара мәче очрау – бәхеткә. Чөнки Австралиядәге очраучы җәнлекләр арасында мәче – иң куркынычсызы.

***

– Сезне елаткан соңгы китабыгыз нинди?
– Математика.
3 нче сыйныф.

Беләсең килсә...

1 Боларның кайсы герой-шәһәр түгел?
а) Ржев;
б) Керчь;
в) Смоленск.

2 Быел рамазан аенда Казанның 36 мәчетендә нинди гамәл башкарыла?
а) тәравих укыла;
б) ифтар уздырыла;
в) хәтем кылына.

3 Ананас кайда үсә?
а) агачта;
б) кырда;
в) куакта.

4 Австралия башкаласы:
а) Сидней;
б) Канберра;
в) Мельбурн.

Җаваплар: 1.а); 2.в); 3.б); 4.б).

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 11293 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 233

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәширият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+